• ВАКЫЙГА •

«ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ» ГАЗЕТАСЫНА ЯЗЫЛ

*2019 елның 1 яртысына язылу бәясе 132 сум. Язылу индексы П4333*

• НӘСЫЙХӘТ •

ДИНЕБЕЗДӘ ЮМАРТЛЫК ҮРНӘКЛӘРЕ

*5 бит*

• СОРАУ – ҖАВАП •

МӘЧЕТКӘ ТӘҺАРӘТСЕЗ КЕРЕРГӘ ЯРЫЙМЫ?

*7 бит*

• ӘҢГӘМӘ •

ЭМОЦИЯ ҺӘМ АВЫРУ

*13 бит*

*№ 12 (281)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *рабигыль-әүвәл – рабигыль-ахыр 1440*

*Декабрь, 2018*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Россиядә ачылган беренче югары һөнәри ислам уку йортына – 20









*Дәвамы 8 биттә*

# Төзәтү колонияләрендә зур эш алып барыла



Камил хәзрәт Сәмигуллин агымдагы ел дәвамында Татарстанда эшләп килгән 9 төзәтү учреждениеләре белән танышып, аларның эшчәнлекләрен мөфтият күзлегеннән чыгып бәяләде.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән берлектә 2016 елдан республикабыз төрмәләрендә җәза үтүче мөселманнар белән зур эш алып бара. Әлеге юнәлеш колонияләрдә экстремизм күренешләрен кисәтү максатыннан тормышка ашырыла. Нәтиҗәдә Татарстан Республикасының барлык төзәтү учреждениеләрендә гыйбадәт бүлмәләре яки мәчетләр эшли, аларда махсус әзерлекле имамнар хезмәт куя. Алар тоткыннарны дини яктан тәрбия кылу белән шөгыльләнәләр: вәгазьләр укыйлар, дини сорауларга җавап бирәләр, Коръән укырга өйрәнергә ярдәм итәләр. Дин әһелләре белән очрашулар һәр атна саен Татарстанның барлык төрмәләрендә уза. Төрмәләргә Нәзарәтнең «Хозур» нәшрияты тарафыннан дини әдәбият, Рамазан ае һәм Корбан бәйрәме уңаеннан күчтәнәчләр тапшырылып тора.



# 2019 – тәфсире елы



Диния нәзарәтенең чираттагы Президиум утырышында 2019 елны атау мәсьәләсе каралды. Президиум әгъзаларына берничә вариант тәкъдим ителгән иде, шул исәптән Әниләр һәм гаилә кыйммәтләре елы, Татар имамнары елы, Коръән һәм Сөннәт елы, Хәйрия елы. Әмма киләсе елда татар дин галимнәре һәм Коръән тәфсире авторлары Шәйхелислам Хәмиди һәм Морат Рәмзинең юбилейлары көтелү уңаеннан, шулай ук киләсе елда Нәзарәт тарафыннан рус һәм татар телләрендә Коръән тәфсирләре чыгарылуны истә тотып, 2019 елны Тәфсир елы дип игълан итәргә карар чыгарылды. Әйтергә кирәк, бу мәсьәләдә киң җәмәгатьчелекнең тәкъдимнәре дә исәпкә алынды – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең Инстаграмдагы рәсми битендә Президиум утырышы алдыннан барлык тегәүчеләрне фикер алышуга чакырган иде. Тәфсир елы кысаларында шулай ук ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасына Шәйхелислам Хәмидинең каберен эзләп табу мөмкинлеге йөкләнде – аның кайда күмелгәне әлегә кадәр билгесез булып кала бирә.

Утырыш барышында Диния нәзарәте Президиумы әгъзалары шулай ук мөфтиятнең бүләкләрен раслады. Махсус бүләкләр – өч дәрәҗәдәге «Мәрҗани» ордены һәм «Бердәмлек» медале дини һәм милли традицияләрне саклауга зур өлеш керткән өчен, дини белем бирүне үстерүгә һәм социаль хезмәттә зур уңышларга ирешкән өчен, милләтара һәм динара татулыкны ныгыту өлкәсендә күрсәткән фидакяр хезмәт һәм башкалар өчен биреләчәк.

# Кукмара мәдрәсәсе 20 еллык юбилеен билгеләп үтте



Кукмара мәдрәсәсенең 20 еллыгына багышланган тантаналы юбилей кичәсе булды. Әлеге чара шәкертләр, мөгаллимнәр катнашында Кукмара мәдәният йортында узды. Уку йортын күркәм юбилее белән тәбрикләргә Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Фән һәм мәгариф бүлеге җитәкчесе Айдар хәзрәт Карибуллин, җирле хакимият вәкилләре, Татарстанның башка мәдрәсә җитәкчеләре, мөгаллимнәр, язучылар, кунаклар – барлыгы биш йөзләп кеше килде. Бәйрәм чарасында мәдрәсә шәкертләре төрле номерлар белән чыгыш ясады – сәхнә күренешләрендә катнашты, мөнәҗәтләр башкарды, вәгазьләр сөйләде. Шулай ук мөгаллимнәр, төрле елларда укып чыккан шәкертләр тәбрикләү сүзләрен җиткерделәр.

Мәдрәсә рәсми рәвештә 1998 елның декабрендә ачыла. Беренче ун елда ул Кукмара Үзәк мәчет бинасында, ә 2008 елдан яңа бинада эшли. Биредә 1500гә якын кеше укып чыккан. Мәдрәсәдә төрле буын вәкилләреннән имам-хатыйблар, ислам нигезләре мөгаллимнәре әзерләнә.

Мәдрәсәдә бүген урта һәм югары дини һәм дөньяви белемгә ия булган мөгаллимнәр эшли. Ришат хәзрәт Курамшин әлеге уку йорты белән 1998 елдан җитәкчелек итә. Моннан тыш ул дини дәреслекләр һәм әдәби әсәрләр авторы буларак та билгеле.

■ dumrt.ru

# «Ислам. Беренче адымнар» сезоны тәмам: намазга баскан 60 кардәшне Татарстан мөфтие сәламләде

10 ноябрьдән 8 декабрьгә кадәр Казанның «Галиев» мәчетендә һәр шимбә «Ислам. Беренче адымнар» проекты кысаларында дәресләр үткәрелде. Курсларда барлыгы 60ка якын кеше катнашты.

«Ислам. Беренче адымнар»ның быелгы сезоны тәмамлану уңаеннан катнашучылар белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин очрашты.



Чарада иң элек катнашучыларның белемнәрен тикшерүгә юнәлтелгән йомгаклау имтиханы булды. Ул үзенчәлекле уен формасында оештырылды. Имтиханнан соң, проектны ябу тантанасы башланды. Очрашу барышында Камил хәзрәт Сәмигуллин проектта катнашучыларга үгет-нәсыйхәтләрен җиткерде. Камил хәзрәт аларны игелекле гамәлләр кылырга чакырып: «Ислам динендәге фарыз гамәлләрне үтәү дә игелек булып санала. Галимнәребез, әгәр дә кеше биш фарызны үтәсә, җиде зур гөнаһтан баш тартса, ин шә Аллаһ, ул Җәннәт белән бүләкләнер, дигән», – диде.

Алга таба очрашу сорау-җавап формасында дәвам итте. Камил хәзрәткә сораулар шактый «яуды» һәм төрле темаларны колачлады. «Сорауларның булуы бик шатландыра, чөнки әгәр шәкертнең сораулары юк икән, димәк, ул яки галим булган, яки бөтенләй бернәрсә белми», – дип билгеләп үтте хәзрәт.

Мисал өчен, чын ир кеше нинди сыйфатларга ия булырга тиеш? «Иң беренче чиратта, ир кеше Раббыбыз турында бервакытта да онытмый. Андый кеше беркайчан да гөнаһ кыла алмый. Икенчедән, ул намаз укый. Өченчедән, зәкят түли. Дүртенчедән, ир кеше Кыямәт, ягъни Кубарылу көненнән куркып яши. Бер кешедә шушы дүрт сыйфат булса, ул Раббыбыз сүзләре буенча, чын ир-ат булып саналачак», – дип билгеләп үтте Татарстан мөселманнары башлыгы.

Моннан тыш, мөфти зияратта дога кылу, тәһарәт алу, намаз уку тәртипләре, ипотека, лоторея, ислам финанслары һ. б. сорауларга җавап бирде.

Алга таба проектта катнашучылар каршында Комлы-Кавәл бистәсе мәчете имамы Зәкәрия хәзрәт Тимганов вәгазь белән чыгыш ясады. Тантанада «Ислам. Беренче адымнар» проектында белем алу турында шәһадәтнамәләр тапшырылды. Очрашу Коръән ашы белән дәвам итте.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты теләге булган һәркемгә тиз арада намаз укырга өйрәнү һәм ислам нигезләре белән танышу мөмкинлеген бирде. Барлыгы 5 дәрес узды. Аларда ислам диненең фазыйләтләре, тәһарәт вә госел, намаз, сира, гакыйдә буенча иң кирәкле мәгълүмат бирелде, хатын-кызлар өчен яулык бәйләү мастер-классы үткәрелде.

Проект күптән түгел исламга килгән, еш кына нәрсәдән башларга кирәклеген, дин нигезләрен кайда үзләштереп булуын белмәгән мөселманнар өчен махсус тормышка ашырылды.

Дәресләр бушлай татар һәм рус телләрендә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен аерым алып барылды. Һәр дәрестән соң катнашучыларга бүләкләр өләшү каралган иде.

Проект үз эшен дәвам итәчәк, аның яңа сезонын яз көнәрендә дәвам иттерергә планлаштырыла. Бу хакта Диния нәзарәте сайтында өстәмә хәбәр ителәчәк.

# Болгарда БИА каршында Бөтенроссия Голәмәләр шурасын булдыру турында фикер алыштылар

Болгарда «II Ш. Мәрҗани укулары: «Россия мөселманнарының институализация процесслары: үткәне һәм бүгенгесе» дип исемләнгән төбәкара конференция узды. Форумның пленар өлеше утырышында Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты. Конференциянең мәртәбәле кунаклары арасында Дагъстан Республикасы мөфтие урынбасары Габдулла Аджимоллаев, Чечня Республикасы мөфтиенең тышкы элемтәләр буенча урынбасары Турко Даудов, Кырым мөфтие урынбасары Руслан Баиров, Махачкаланың Үзәк мәчете имамы Зәйнулла Атаев һәм Россиянең башка танылган мөселман дин әһелләре, фән эшлеклеләре, Болгар ислам академиясенең профессор-мөгаллимнәр составы һәм студентлары, башка дини мәгариф оешмаларыннан делегатлар катнашты.




Конференциянең тантаналы ачылышында иң мөһим сораларның берсе булып Болгар ислам академиясе каршында Бөтенроссия Голәмәләр шурасы проектын булдыру мәсьәләсе торды. Бу төр институтны булдыру ихтыяҗы Россия мөселманнары өммәтенең төрлелеге һәм шуңа бәйле рәвештә, глобаль дини сораулар буенча барлык мөселман төркемнәрнең мәнфәгатьләрен истә тоткан һәм килешенгән уртак карарлар чыгару зарурияте бәйле. Бу хакта үзенең сәламләү сүзендә Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин да әйтте. Ул, мөселман галимнәренең берләшүе Россиядә Голәмәләр институтының абруен арттыру өчен мөһим, дип ассызыклап узды.

Бөтенроссия Голәмәләр шурасын булдыру мәсьәләсенең әһәмияте турында ТР мөфтие урынбасары, Болгар ислам академиясе һәм Россия ислам институты ректоры Рәфикъ хәзрәт Мөхәммәтшин да сөйләде. Ул Россия мөселман җәмәгатьче-легендәге икътисади, социаль проблемаларны хәл итүдә Голәмәләр тырышлыгын берләштерүне бүгенге заман өммәтенең өстенлекле бурычлары рәтенә кертте.

Пленар утырыш кысаларында БИА каршындагы Бөтенроссия Голәмәләр шурасының эш принциплары проекты да каралды.

■ dumrt.ru

2019 ел Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнарының диния нәзарәте тарафыннан Коръән тәфсире елы дип игълан ителде. Шул уңайдан халкыбызда аеруча киң таралган, дистә еллар дәвамында укып-өйрәнелеп килгән тәфсирләребезне карап китик.

# «Ногмани тәфсире»н Ногмани гына язганмы?

Татарлар арасында «Ногмани тәфсире»н белмәүчеләр бик аздыр. Ул Идел буенда XIX йөз ахырыннан башлап иң киң таралган Коръән тәфсирләренең берсе булып тора. Аның авторы турында ниләр мәгълүм, хезмәтнең тарихы нинди булган соң?

Авторның тулы исеменә килгәндә, чыганакларда ул ике төрле очрый: Ногман бине Әмир бине Госман һәм Ногман бине Сәбит Әс-Сәмәни. Әс-Сәмәни тәхәллүсе руханиның Сәмән авылыннан булуын сөйли.

Ногман XIX гасырның беренче яртысында яшәгән, туган елы төгәл билгеле түгел. Җәмил Зәйнуллин хезмәтләреннән Ногман хәзрәтнең Казан губернасының Курса авылында күренекле татар мәгърифәтчесе, Нәкышбәнди тарикатенең шәехе Әбү Насыйр Габденнасыйр бине Ибраһим Әл-Курсавидан белем алганы мәгълүм. Курсада мәдрәсә тәмамлаганнан соң, Ногман үзе дә мәдрәсәдә укыта, ә остазы вафатыннан соң, Коръән тәфсире өстендә эшли башлый. Әмма бу зур хезмәтен тәмамлый алмый. Остазы кебек үк, Ногман да хаҗга барганда вафат була, Төркиядә Өскедар шәһәре (хәзер Истанбулга керә) зиратында күмелә. Башка фикер буенча, Ногман Дагъстан якларына китеп, анда мөгаллимлек иткән, шунда вафат булган.

«Ногмани тәфсире»нең бер нөсхәсендә автор турында мәгълүмат китерелә, шуның буенча Ногмани турында түбәндәгеләр мәгълүм. Ул Стәрлетамак өязе Сәмән авылыннан (хәзерге Башкортстан Республикасы) Әмин бине Госман исемле адәмнең улы. Казан губернасы Курса авылында мәшһүр Әбү Насыйр бине Габденнасыйр бине Ибраһимда гыйлем ала. Бик зирәк һәм сәләтле булып, остазыннан күп файда алды. Кайбер нечкә, четерекле мәсьәләләрне үзләштереп, яшьтәшләреннән аерылып торды. Остазының абыйсы Габделхалик шәехнең кызына өйләнә. Остазы хаҗга киткәч, аны алыштырып тора, дәресләр бирә, остазы башлаган тәфсирне тәмамларга теләп, тәэзәтмәләр кертә, үзенең тәфсирен яза башлап, аны «Әл-Кәһеф» сүрәсенә кадәр эшли.

Тәфсирнең язылу вакыты һәм урыны төгәл билгеле түгел. Җ. Зәйнуллин фикеренчә, бу 1831–1832 еллар тирәсе. Ногманиның башка әсәрләре булганмы, кызганычка, бүгенге көндә бу мәгълүм түгел.


Курсави да, Ногман хәзрәт тә үз хезмәтләрендә Ибне Әл-Әсир (Гыйзәддин Әбү Хәсән бине Мөхәммәд Әл-Җәзири), Имам Куртуби һәм башка гарәп вә фарсы авторларының тәфсирләренә таянган.

Ногмани тәфсире беренче тапкыр 1896 елда нәшер ителә. Хезмәт таралып, Идел буе территориясендә авторга югары бәяләмә бирелә. Билгеле, тәфсир төзүгә тирән гыйлемле кеше генә алына ала, Ногмани хезмәте авторның бу сыйфатка ия булуын раслый. Аның Курсавидан кала кемдә һәм кайда гыйлем алуы, хезмәтен кайда язуы мәгълүм түгел.

«Ногмани тәфсире»н шартлы рәвештә өч өлешкә бүлергә мөмкин. Җ. Зәйнуллин билгеләвенчә, бүгенге көндә татарларга билгеле тәфсирне Габденнасыйр Курсави яза башлый, аны тәмамлый алмыйча, хаҗга барганда вафат була. Тәфсирнең икенче өлеше – Ногман хәзрәтнең хезмәте, ул тәфсирне остазы тукталган урыннан дәвам иттергән. Ногман Әс-Сәмәни «Әл-Кәһеф» сүрәсендә туктала. Шулай ук өченче автор да булган.

Тәфсирне нәшер иткәндә, басмаханә җитмәгән сүрәләрне, «Әл-Кәһеф»тән «Әл-Фәтех» сүрәсенә кадәр, төрек «Әт-Тибьян» тәфсиреннән алып куйган. Татарлар арасында госманлы тәфсирләре киң таралган була. Р. Фәхретдин фикеренчә, татар телендә тәфсир төзелгәндә, төрек рухание Мөхәммәд Әйнтабинең 1110 елда тәмамланган «Тәфсирүт-Тибьян» хезмәте файдаланырга мөмкин булган.

Бүгенге көндә КФУның Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәдә Ногмани тәфсиренең кульязмалары саклана, әмма алар барысы да күчермә, ә кульязманың асыл нөсхәсе (оригиналы) әлегәчә


تفسیر نعمانی
( صاحب التفسیر ملا نعمان نك ترجمهٔ حالی )
( سبب طبع )
طابع وناشرلری :
ابراهیم ادریسف وشرکاسی
قزان.

табылмаган. Бу нөсхә тәфсир чыккач басмаханәдә яндырылган, дигән фикер дә бар. Тәфсирнең күчерелгән кульязмалары Ногман тәрҗемә иткән сүрәләрдән генә тора. Мисал өчен, Сөләйман Хәмидулла улы күчергән нөсхә ике өлештән тора. Беренче өлешкә «Әл-Бәкара», «Әли Гыймран», «Нисә», «Мәидә», «Әнгәм» сүрәләре кергән. Икенче өлеш «Әгъраф», «Әнфәл», «Тәүбә», «Һуд», «Йосыф», «Рәгыд», «Ибраһим», «Хиҗер», «Нәхел», «Бәни Исраил» сүрәләреннән тора. Бүгенге көндә татарлар арасында таралган «Ногмани тәфсире» тулы булса да, Ногман тарафыннан шушы саналган сүрәләр генә тәфсир ителә.

# «Әл-Фәваид» тәфсире

Татар телендә язылган һәм киң таралган булган янә бер тәфсир – «Әл-Фәваид» тәфсире.

Аның авторы Мөхәммәдзариф Әмирхан (1852–1921) – тарихчы, күренекле татар мөгаллиме, рухани, язучы Фатыйх Әмирханның әтисе. Күп еллар дәвамында ул «Әмихания» мәдрәсәсендә укыта.

Мөхәммәдзариф 1853 елның 10 гыйнварендә туа. Ногман кебек үк, ул да Курса авылында гыйлем ала. Аннан соң укуын Казан губернасы Норлат авылы мәдрәсәсендә дәвам итә. Шәкерт вакытында ук Коръәнне тулысынча ятлый. Тавышы бик матур булганлыктан, еш кына мөәзин булып та тора.

1874 елда, мәдрәсәне тәмамлап, Яңа бистә мәчетендә имам булып торган этисенең ярдәмчесе булып урнаша. 1881 елда Бибирабига исемле мөгаллимәгә өйләнә.

Мөхәммәдзариф имам бөек шагыйребез Габдулла Тукайның җеназасын укый. Бу халыкның хәзрәткә ышанычын һәм мәхәббәтен күрсәтеп тора.

Хәзрәт 1921 елда ваба авыруыннан (холера) вафат була.

Мөхәммәдзариф Әмирхан – татар телендәге иң беренче тәфсирләрнең берсе булган «Тәфсир Фәваид»ның авторы. Хезмәтнең нигезе – Мөхәммәд Җамалетдин Әл-Һинди Әд-Дәхләвинең «Фәтех Әр-Рахман фи тәфсир»е, «Мәдарик» тәфсире, «Зөбәде әсәр Әл-Мәһаиб вәл-Әнвар». Мөхәммәдзариф хәзрәт гарәп телен белмәүчеләр үз туган телләрендә Коръән аятьләренең мәгънәләре белән танышa алсын дигән максат куйган. Мөфәссир фикеренчә, төрки телдә язылган тәфсир бик кирәк булган.

Әлеге хезмәтнең кульязма нөсхәләре шулай ук КФУның Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә фондларында саклана.

Хезмәт өч өлештән тора. Аның башында автор тәфсирнең ни өчен «Фәваид» («Файдалар») дип аталганын аңлата: «Чөнки тәфсир Коръән аятьләренең мәҗмугасы булып тора һәм үз эченә кешеләрне кызыксындырган мәгънәләрнең аңлатмасын ала. Коръән Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән була».

Тәфсирне нәшер итәргә 1885 елның 10 гыйнварендә Петербургта рөхсәт бирелүе турында языла.

Киләсе биттә «Әл-Фатихә» сүрәсенең тәфсире башлана. Китап алтынчы сүрә, «Әл-Әнгәм» белән төгәлләнә. Ул 252 биттән тора.

Тәфсирнең бу өлеше һиҗри буенча 1303 елда Казанда Мөхәммәдзариф акчасына бастырылуы да искәртелгән.

Икенче том «Әл-Әгъраф» сүрәсеннән башланып, «Бәни Исраил» сүрәсенең соңгы аяте белән тәмамлана, 264 биттән тора. Бу китапны бастыруга 1886 елда Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан рөхсәт бирелгән.

Өченче том «Әл-Кәһеф» сүрәсе белән башланып, 37 нче «Саффат» сүрәсе белән тәмамлана, 361 биттән тора. Әлеге тәфсир турында билгеле булган мәгълүматлар менә шушылар.

Ногман бине Сабитның да, Мөхәммәдзариф Әмирхан тәфсире дә татарлар гына түгел, башка төрки халыклар тарафыннан да дистә еллар дәвамында укылган, өйрәнелгән, башка дини хезмәтләр өчен нигез булып торган. Бу тәфсирләрнең күпсанлы күчерелмәләре аларның киң таралган булуын дәлилли. Әлеге хезмәтләр халкыбызда дини әдәбият үсешенә зур этәргеч булып торган.

■ **Сәхифәне Рәмзилә Шафикова әзерләде**

# Динебездә юмартлык үрнәкләре

## Сәхәбәләрнең юмартлыгы

Сәхабәләр юмартлыкның өстенлеген һәм әһәмиятен бик яхшы белгәннәр, шуңа да кайсы гына сәхабәне алсак та, аның үз малын дин юлында кызганмавына тап буласың. Алар үзара яхшы гамәл кылуда ярышканнар.

### Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам әйткән булган: «Һичшиксез, миңа иң күп ярдәм күрсәткән кеше – Әбү Бәкер, ул минем өчен беркайчан да малын кызганмады һәм һәрвакыт миңа дус булды» (Мөслим). Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам Әбү Бәкернең малын үз малын куллангандай дин юлында сарыф иткән. Шул рәвешле, пәйгамбәрлек килгән вакытта Расүлебез галәйһиссәлам өчен бу бик зур таяныч булган.

### Госман радыяллаһу ганһе

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң илдә корылык башлана. Кешеләр ярдәм сорап Әбү Бәкер янына килә, ләкин дәүләттә бер тиен акча калмаган була. Шул вакытта Госман радыяллаһу ганһенең азык-төлек белән төялгән кәрваны кайта. Сәүдәгәрләр аның янына ашыга. Ләкин Госман радыяллаһу ганһе: «Мин малымны иң зур бәя тәкъдим иткәнгә генә бирәм», – дип әйткән. Һәм ул шулай эшли дә: бөтен азыкны Мәдинәдә яшәүчеләргә таратып чыга һәм алардан моның өчен бер тиен акча алмый, чөнки Госман радыяллаһу ганһе Аллаһы Тәгаләнең бүләге кешеләр тәкъдим иткәннән күпкә артыграк булуын яхшы белә. Икенче вакытта Госман радыяллаһу ганһе тулы бер гаскәрне коралландыруны үз өстенә ала.

### Гомәр радыяллаһу ганһе

Тирмизи һәм Әбү Давыд җыентыкларында түбәндәге хәдис китерелә: Гомәр радыяллаһу ганһе әйткән булган: «Аллаһының Илчесе безгә үз малларыбыздан мохтаҗларга өлеш чыгарырга боерды. Мин дә үз малымны сарыф иттем. Соңыннан Расүлебез галәйһиссәлам: «Үз гаиләңә нәрсә калдырдың?» – дип сорады. Мин: «Яртысын», – дип җавап бирдем. Соңыннан ул Әбү Бәкергә шул ук сорауны бирде. Әбү Бәкер: «Мин аларга Аллаһы Тәгаләне һәм Аның Расүлен калдырдым», – дип җавап бирде. Мин шул чакта: «Дөреслектә, мин беркайчан аны (Әбү Бәкерне) уздыра алмам», – дип әйттем».

### Сәгыйть бине Гас

Бер кеше Сәгыйть бине Гаска үтенеч белән мөрәҗәгать иткән. Сәгыйть йөз мең дирһәм бирергә боергач, бу кеше елап җибәргән. Ул: «Нигә елыйсың?» – дип сораган. Тегесе: «Җир синең кебек кешене йотачагы өчен елыйм!» – дип җавап кайтарган. Шуннан соң Сәгыйть аңа тагын йөз мең бирергә боерган.

### Гали радыяллаһу ганһе

Риваять кылулары буенча, бервакыт Гали кәррамәллаһу вәҗһәһу елап җибәргән. Аннан: «Ни өчен елыйсың?» – дип сораганнар. Ул: «Миңа инде җиде көн беркем дә кунакка килми. Мин болай итеп Аллаһы миңа Үзенең нәфрәтен белдерә дип куркам», – дип җавап биргән.

### Габдрахман бине Гауф

Бервакыт Мәдинәгә аның кәрваны кайта: җиде йөз дөягә ашлык, он һәм башка азык-төлек төялгән була. Гайшә радыяллаһу ганһә Расүлебез галәйһиссәламнән аның җәннәткә шуышып керәчәген ишеткәч, бу хәбәрне Габдрахман бине Гауфка җиткерә. Шатлыгыннан ул бөтен кәрванын Аллаһы юлында сарыф итәргә боера. Шул вакыйгадан соң Габдрахман ачык һәм яшерен рәвештә садака өләшә башлый. Әүвәл кырык мең көмеш дирһәм, соңыннан кырык мең алтын динарны мохтаҗларга тарата, күпмедер вакыт үткәч – 200 мыскал алтынны. Моннан тыш, хәрбиләргә ике мең ат бүләк итә. Үзе вафат булгач та, ул бик зур мирас калдыра, шул исәптән, Бәдер сугышында катнашканнарга һәм Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәламнең хатыннарына да. Шундый байлыкка ия була торып, Габдрахманның әхлагы камил саклана.



## Исламда хатын-кызларның юмартлыгы

Ислам тарихына күз салсак, мөселман хатын-кызларының да җәмгыятькә үз өлешеләрен керткәннәрен күреп була. Мөслимәләрнең дә мөһим бер әхлакый сыйфаты булып юмартлык тора. Һәм шундый киң күңелле хатын-кызлардан – Әбү Бәкернең кызлары Гайшә һәм Әсма. Алар турында Әсманың улы Габдуллаһ: «Мин гомеремдә беркайчан туган апам Гайшә һәм әнием Әсмадан юмартрак хатын-кызлар күрмәдем, гәрчә аларның юмартлыгы төрле булса да. Апам аз-аз акча туплап, һәм җитәрлек күләмдә җыелгач, аны мохтаҗлар арасында бүлеп бирә иде. Әнием исә, үзендә нәрсә булса да барлыкка килүгә, киләсе көнгә хәтле дә түзеп тормыйча, шул ук көнне аны мескеннәргә илтеп тапшыра иде», – дип әйткән.

### Гайшә радыяллаһу ганһә

Гайшә радыяллаһу ганһә киңкүңеллелек, талымсызлык һәм юмартлык белән аерылып торган. Ул ачлык һәм ярлылыкка сабыр иткән. Үзе турында онытса да, мохтаҗлар турында беркайчан да онытмаган, аларга һәрдаим ярдәм итәргә тырышкан.

Шулай бервакыт хатын-кызлардан берсе Гайшә радыяллаһу ганһәгә һәдия (бүләк) җибәргән. Әмма Гайшә аны кабул итми. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам моны белгәч: «Әй, Гайшә, ни өчен һәдияне кабул итмәдең?» – дип сорый. Ул: «Аны җибәргән кеше миннән мохтаҗрак булганы өчен, йә, Расүлуллаһ!» – дип җавап биргән. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Син бүләкне кабул ит, ләкин соңрак ул хатынга зуррак һәдия бир һәм үзенә ярдәм ит», – дип әйткән.

### Сәүдә бинте Зәмга

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең башка хатыннары да юмартлык күрсәтүдә калышмаган. Шул исәптән Сәүдә бинте Зәмга радыяллаһу ганһә дә. Бервакыт Гомәр радыяллаһу ганһе аңа бүләк итеп акча җибәргәч, ул соңгы дирһәменә кадәр Аллаһы юлында таратып бетергән.

### Зәйнәб бинте Җәхеш

Иренең үрнәгенә ияреп, Зәйнәб бинте Җәхеш радыяллаһу ганһә дә юмарт һәм тыйнак була. Шулай көннәрнең берендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм барлык хатыннары барында: «Миннән соң сезнең иң озын куллыгыз миңа иярәчәк», – дип әйткән. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән соң беренче булып Зәйнәб бинте Җәхеш үлгән. Шул вакытта Пәйгамбәр хатыннары аның «иң озын куллы» (юмарт) булуын белгәннәр, чөнки Зәйнәб кул эшләрен яратып башкарган (тире эшкәрткән, куннан киемнәр теккән, дисбеләр ясаган) һәм ярлыларга шул малдан садакалар тараткан. Аның күркәм сыйфатлары турында Гайшә радыяллаһу ганһә болай дигән: «Мин Зәйнәбтән дә тәкъварак, гаделрәк, туганлыкны ныграк саклаучы, садака таратуда аяусызрак кеше күрмәдем. Шулай итеп, ул Аллаһы Тәгаләгә якынлаша иде».

■ **Гөлназ Ситдикова**

# НАМАЗ – ДИННЕҢ ТЕРӘГЕ



Галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барча хәмде-сәналәребез булса иде. Аның хак хәбибе Мөхәммәдкә дә йөрәкләребезнең түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһыга мөрәҗәгать итеп, һәрвакыт Аңа итагатьтә булыгыз һәм Аңа гөнаһлы булудан сакла写ыгыз, билгеләнгән намазларыгызны вакытында укыгыз, һәм һичнәрсәне Аллаһыга тиң кылмагыз, мөшрикләрдән булмагыз».**

«Рум», 30:31

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз диннең терәге. Намаз кылмаган кеше – динне җимерүче», – дип әйткән. Ошбу хәдистән аңлашылганча, нигезсез йорт була алмаган кебек, намазсыз Ислам да, мөселманлык та була алмый. Намаз уку һәр мөселманга да үзенең бәхетле булуы һәм үз мәнфәгате өчен кирәк. Үзләрен мөселман дип, әмма намаз укырга вакытым юк, дип йөрүчеләр, ислам динен торгызу урынына, ислам динен җимерүчеләр булалар икән. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: **«Мин кешеләрне дә, җеннәрне дә Миңа гыйбадәт кылсыннар өчен яраттым».**

«Зарият / Таратучы», 51:56

## Намаз – гыйбадәтнең иң олысы

Адәм баласы яралтылганнан соң бары тик сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәригатендә генә (гыйбадәт кылу гыйлемнәре белән бергә) көненә биш тапкыр намаз уку вазифасы йөкләтелгән. Һәм бу үзен мөэмин-мөселман дип йөргән кеше өчен, Аллаһы Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкер кылу өчен, Аның рәхмәте белән йөкләнгән хөрмәтле вазифа булып тора. Иман китергәннән соң намаз – гыйбадәтләрнең башы һәм иң изгесе. Намазның әҗер-саваплары, файдалары санап бетергесез. Шуларның берсе турында пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Намаз – мөэминнәрнең мигъраҗы», – дип әйткән. Мигъраҗ – бөекләр янына күтәрелү. Ягъни, без намаз укыганда Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә каршына басып, Аның колы икәнлегебезне таныйбыз, дәлиллибез.

Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз турында мондый хәдис-шәриф әйтеп калдырган: «Намаз – мөэминнең нуры ул. Мөселманның өйдә кылган намазы өен нурландырыр». Тагын бер хәдистә болай дип әйтелә: «Өйләрегезне намаз кылып, Коръән укып нурландырыгыз». Ягъни: «Фарыз намазларны мәчеттә укып, нәфел намазларын өегездә укып, өйләрегезне нурландырыгыз», – ди. Елына бер тапкыр азан әйтеп, йә булмаса берәр бабай чакырып, аннан азан әйттереп кенә өйләрне нурландырырга бик авыр була, ә намаз укып ул һәрвакыт нурлана.

Икенче бер хәдистә: «Аллаһының Үзен күргән кебек гыйбадәт кыл», – дип әйтелә, ягъни, Раббыңа гыйбадәт кылганда, намаз укыганда, Аны күргән кебек ихлас күңел белән, күңел рәхәтлеген тоеп, барлык чит булган нәрсәләрне онытып, өстеңә йөкләнгән гыйбадәт кылу, коллык бурычларын җиренә җиткереп үтәүне аңлата. Шул вакытта намазның тәмен белергә була. Күзләребез белән Раббыбызны күрмәсәк тә, ул безне күрә, барлык уй-фикерләребезне дә белеп тора. Без бит Аллаһы Тәгаләнең йорты булган мәчеткә гыйбадәт кылырга килгәндә Аллаһы Тәгаләнең:

**«Үзеңә үлем килгәнчегә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл»,**

«Хиҗер», 15:99

– дигән әмерен истә тотып киләбез. Ошбу әмерне мәчеткә килгәндә генә түгел, башка вакытларда да онытмасак иде.

## Намаз – эшләрнең иң хәерлесе

Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гамәлләрегезнең иң фазыйләтлесе, эшләрегезнең иң хәерлесе – намаз уку», – дип әйткән.

Икенче хәдистә: «Намаз – һәр хәерлелнең ачкычы. Намаз – җәннәтнең ачкычы», – дип әйтелә. Ошбу хәдисләрдә иман китергәннән соң иң хәерле эш – намаз уку диелә. Иман-ышану беренче дәрәҗәдә, ә намаз икенче дәрәҗәдә, чөнки башта Аллаһы Тәгаләгә иман китермичә, (Барлыгына, Берлегенә) ышанмыйча, намаз укып булмый бит.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: **«Миңа гына гыйбадәт кыл вә Мине зикер итәр өчен намаз укы».**

«Та Һа», 20:14

Кеше кемне яки нәрсәне яратса, шуны хәтерендә даими сакларга, һәрвакыт аны аңларга, аның турында күбрәк белергә тырыша. Кешенең фикерендә, уенда нәрсә булса, аның зикере дә, сүзе дә шуның турында гына була. Аллаһы Тәгаләне барча мәхлүкъләрдан да күбрәк яратучы Раббысы турында күбрәк уйлап, Аның әмерләрен үтәргә тырышып, намазын вакытында укый да, ин шә Аллаһ, җәннәтле булачак. Ә инде акчаны, малны күбрәк яратучы – шул малга, акчага «табына» башлый. (Аллаһы Тәгалә аның йөрәген Үзенә гыйбадәт кылудан азат иттерә). Ул кеше: «Миңа күбрәк булсын; башкалардан зуррак дәрәҗәле урында булыйм», – дип тырышып, ахыр чиктә үзенең нәфесе артыннан иярә. Кайбер кешеләр шәйтанга гыйбадәт кыла башлый, һәм шуның белән ширек кылганын сизми дә кала. Кыямәт көнендә, Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын, җәһәннәмгә керүе бар.

## Намаз укучыга фәрештәләр догада була

Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «(Намаз укыган кеше) аның өчен фәрештәләрнең ничек итеп дога кылганын күрсә, ул кеше намаздан һич аерыла алмас иде», – дип әйткән. Кеше өеннән мәчеткә намаз укырга дип чыгып киткәннән алып, өйгә кайтып кергәнгә кадәр барлык вакыты намазда булу дип санала. Фәрештәләр шул вакыт аралыгында аның өчен догада булалар.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Дөреслектә, хак мөэминнәр газаптан котылып, мәңгелек сәгадәткә (бәхеткә, уңышка) ирештеләр. Алар намазларын хошугъ (түбәнчелек), әдәп белән, Аллаһыдан курку белән укыйлар».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:1-2

Риваятьләргә караганда, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, намаз укыганда, башта күзләрен күк тарафына юнәлтеп укыган. Ошбу аять иңгәннән соң, намазда сәҗдә урынына карап укый башлаган. Гомумән, намаз укучы карашын намаз урынына юнәлтә. Намаздагы хошугълык (түбәнчелек, әдәп) – шул намаз укучы кеше уң һәм сул якларында кем торганны да белмәүгә кайтып кала, дисәк тә була. Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә уңышка ирешүнең төп шарты итеп Үзе каршында түбәнчелекле булуны билгеләгән.

## Һәр намазның үз вакыты

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Фарыз намазы вакыты җиткәч тиешенчә тәһарәт алучы, ә намаз вакытында тиешле түбәнчелек күрсәтүче һәм барлык сәҗдәләрне тиешенчә үтәүче һәрбер мөселманга, зур гөнаһлар кылмаган булса, аның бу намазы белән, һичшиксез, аңа кадәр кылган гөнаһлары гафу ителәчәк. Бу һәрвакытта да шулай калачак», – дип әйткән. Шулай ук бервакыт пәйгамбәр Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Гамәлләрнең кайсы иң яхшы санала?» – дип сораганнар. Ул: «Намазны үз вакытында уку», – дип әйткән.

Намазын вакытында укучы кеше – Раббысы Аллаһыга буйсынган хәлдә, гөнаһлардан сакланып, Аллаһыга ширек кылудан тыелып яшәүче була. Шуңа да гаилә башлыгы булган ир кеше намазларны үзе укырга һәм динне гаиләсенә дә өйрәтергә бурычлы ителгән.

Хәдис-шәрифтә: «Мөэмин белән имансызларны аера торган нәрсә – ул намаз», – дип әйтелә. Әмма безнең башка кешегә: «Син – имансыз, чөнки син намаз укымыйсың», – дип әйтергә хакыбыз юк (кешенең күңелендә нәрсә икәнен белеп булмый). Кешегә исә Аллаһы Тәгаләдән үзенә һидаять бирүен, намаз укучылар рәтеннән кылуны сорарга кирәк.

Раббым Аллаһ, өстебезгә йөкләгән намазларны үземә, гаиләмә, нәселемә һәм дә мөэмин-мөселман кардәшләремә кимчелек, хатасыз үтәп, Үзеңнең ризалыгыңа ирешергә, рәхмәтең белән җәннәтеңә керергә насыйп әйләсәң иде. Әмин!

■ **Равил хәзрәт Нуруллин,
Яр Чаллы шәһәренең «Туфан» мәчете имам-хатыйбы**

## Миңа сакларга бирелгән акчаны урладылар. Хәзер мин әҗәтле булып калдыммы?



**Сорау:** Минем каенанама 80 яшь, ул ялгызы яши. Соңгы юлга озатырга дип җыйган акчаларын югалтырга куркып, аларны безгә сакларга бирде. Бер көнне, без барыбыз да эштә вакытта, фатирыбызга кереп, безнең кайбер әйберләребезне, әни биргән акчаларны да урлаганнар. Бездә әнигә кайтарырлык акча хәзерге вакытта юк, минем өчен бу зур сумма. Бик борчылам, мин әҗәтле булып калдыммы?


**Җавап:** Шәригать буенча, кеше аңа сакларга дип бирелгән малны (əманәтне) сакларга һәм хуҗасына кайтарырга тиеш. Бу хакта «Нисә» сүрәсенең 58 нче аятендә әйтелә: **«Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә сезгә әманәтләрен әһелләренә тапшырырга әмер итәдер ...»**

«Мохтасар Әл-Кудури» китабының «Әл-Вәдига» бүлегендә: «Әл-вәдига – ул кешегә сакларга дип тапшырылган әйбер. Бу кешегә бирелгән әйбер югалса, ул югалган әйбер өчен каза кайтарырга тиеш түгел», – диелгән.

Сезнең очракта сез бурычлы түгелсез, чөнки акчаларның урлануында сезнең гаебегез юк. Шәригать буенча сез акчаны кире кайтарырга тиеш түгел. Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Авызга яңгыр яки кар эләксә, намаз бозыламы?



**Сорау:** Кайвакыт мөселманнарга намазны юлда укырга туры килә. Әгәр дә мин намазны урамда укырга булсам, һәм намаз вакытында авызыма кар бөртекләре эләгеп, мин аларны йотсам, намазым бозыламы?

**Җавап:** Әгәр намаз вакытында сез кар бөртекләре йотсагыз, намазыгыз бозылачак. «Әл-Фәтәва Әл-Һиндия» китабында: «Әгәр намаз вакытында кешенең авызына яңгыр, бозлы яңгыр тамчылары яки кар эләксә, һәм кеше аларны йотып җибәрсә, аның намазы бозылачак», – дип әйтелгән.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Хатын-кызга чәчен тулысынча кырдырырга ярыймы?

**Сорау:** Хатын-кыз чәчен кырдырса, ягъни тулысынча алдырса буламы?

**Җавап:** Хәнәфи һәм мәлики мәзһәбләре галимнәре фикеренчә, хатын-кызга, җитди сәбәпләрсез, башындагы чәчләрен тулысынча кырдыру тыелган. Моңа дәлил булып Әбү Муса Әл-Әшгаринең сүзләре килә: «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күп сөйләшүче һәм чәчләрен кырдыручы хатын-кызларга катнашы булмаган» («Фәтхүл-Бәри» Әл-Бохари шәрехе, 3т., 165 б). Башка бер хәдистә Пәйгамбәребезнең хатын-кызга чәчләрен кырдырырга рөхсәт итмәве китерелә (Әт-Тирмизи, 3т., 248 б). Хәсән Әл-Бәсри: «Хатын-кызлар өчен чәчләрен кырдыру мүсләгә тиң (мүслә – тәннең бер әгъзасын (кул, аяк, колак кебек) кисеп алу, ә бу тыелган)», – дип әйткән. Ә әгәр хатын-кыз гозерле икән (ягъни аның кискен сәбәбе бар) яки авыру сәбәпле чәчен кырдырса, хәнәфи мәзһәбе буенча бу рөхсәт ителә (Ибне Габидин, «Раддел-Мохтар», 2т., 182 б).

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Мәчеткә тәһарәтсез керергә ярыймы?

**Сорау:** Мин кайвакыт тәһарәтсез килеш мәчеткә керәм. Бу гөнаһмы? Мәчеттә йокларга һәм ашарга ярыймы?


**Җавап:** Күпчелек галимнәрнең фикере буенча, мәчеткә тәһарәтсез керергә рөхсәт ителә. Мәчеттә йоклау һәм ашау – мәкруһ (гөнаһлы түгел, әмма шелтәләнә торган гамәл). Игътикәф кылучыларга мәчеттә ашарга һәм йокларга рөхсәт ителә.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Ир-атларга түбәтәй кияргә кирәкме?

**Сорау:** Кайбер ир-атлар мәчеткә түбәтәйсез килә. Безнең мәзһәбтә түбәтәй кию кирәк саналамы, аңлатып китегез әле.

**Җавап:** Намаз укыганда һәм намаздан тыш та



башка кию мөстәхәб – кирәкле, хупланган гамәл булып тора. Күренекле галимебез имам Әш-Шурунбулялинең «Мәракил-фәләх» китабында: «Намазда мәкруһ гамәлләрнең берсе – намазны яланбаш уку», – диелә (202 б). Өстәмә итеп шуны китерергә була: «Кемдер гамьсезлек белән намазны яланбаш укыса, бу – мәкруһ. Хәтта тыйнаклык күрсәтеп яланбаш укыса да, бу да мәкруһ булып тора».

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

## Кыйблага таба аякларны сузып утырырга ярыймы?



**Сорау:** Күп тапкыр мәчетләрдә кешеләрнең кыйбла тарафына аякларын сузып утырганны күргәнем булды. Алай утырырга ярамый дип укыган идем, бу дөресме?

**Җавап:** Кәгъбә (кыйбла) тарафына аяк сузу (хәтта йоклаганда яки белмичә дә) мәкруһ булып тора. Шулай ук аякларны Шәригать буенча китаплар ягына сузып утыру, якынлык кылганда аякларның кыйбла ягында булуы да мәкруһ. Бу хакта имам Сәрахсинең «Әл-Мөхит» китабында әйтелә.

■ **ТҖ мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Россия ислам институтына – 20

Казанда Россия ислам институтының 20 еллыгына багышланган чаралар уздырылды. Шул уңайдан ике көнлек Мөселман мәгариф оешмалары мөгаллимнәренең VI Халыкара форумы оештырылды. Форум эшендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, шулай ук Россия Президенты Администрациясе, ТР мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре, мөселман илләреннән килгән кунаклар һәм илчеләр, югары һәм урта мөселман белем бирү оешмалары җитәкчеләре, мөгаллимнәре катнашты.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында 90 нчы елларда төзелгән мөселман уку йортларының ислам теологиясе, ислам тарихы һәм мәдәнияте өлкәсендә квалификацияле белгечләр әзерләү максатын куюларын һәм институтның әлеге бурычларны уңышлы хәл итүен билгеләп үтте. Аерым алганда, вуз оешу дәверен уңышлы үтте һәм ул хәзер илебезнең әйдәп баручы мөселман уку йортларыннан санала, дигән фикерен җиткерде ул. Татарстан Президенты шулай ук киләчәктә фәнни һәм уку-укыту эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләренә дә аерым игътибар бирергә кирәклекне әйтте: чит ил вузлары һәм фәнни-мәгариф үзәкләре белән партнерлык мөнәсәбәтләрен активлаштыру, фәнни-мәгърифәтчелек һәм нәшрият эшчәнлеген үстерү буенча эшне көчәйтү һ. б.





РИИ юбилее уңаеннан Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча XI Бөтенроссия олимпиадасы, Ислам мәгарифе Советы утырышы, мөселман халыклары мәдәнияте фестивале оештырылды. Президент әлеге чараларның Татарстан һәм илебез мөселман берләшмәләре тормышында зур вакыйгаларга әверелүенә өметен белдерде һәм Россия ислам институты ректоры Рәфыйкъ Мөхәммәтшинны «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» орден медале белән бүләкләде.

Әлеге юбилей чараларында катнашып, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин шулай ук Россия ислам институты җитәкчелеге, хезмәткәрләре һәм шәкертләренә ихлас күңелдән тәбрикләү сүзләрен ирештерде: «Сезнең коллективның мәгариф, уку-укыту эшендәге зур нәтиҗәләре, тирән нигезле фәнни тикшеренүләре, белгечләрнең югары һөнәри дәрәҗәсе, үз эшләренә бирелгәнлекләре Россиядәге ислам вузлары арасындагы мәгариф киңлегендә университетка әйдәп баручыларның берсе булырга ярдәм итә», – дип белдерде Камил хәзрәт. Татарстан мөселманнары башлыгы үзенең үгет-нәсыйхәт сүзләрен Коръән аятьләре, Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләре белән тулыландырды һәм Ислам диненең һәрвакытта белемле булырга чакырганына басым ясады: «Шөкер, бүген Россия мөселманнарына ислам буенча белем алу өчен ерак йөрисе юк. Россия ислам институты Татарстанның гына түгел, илебез масштабындагы мөселман мәгариф системасында мөһим бер өлеше булып тора».

Хәзрәт озак еллар дәвамында динебезнең үсешенә куйган хезмәте өчен Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Татарстан өммәте үсешенә керткән өлеше өчен» истәлекле медале белән Россия ислам институты ректоры Рәфыйкъ хәзрәт Мөхәммәтшинны, институт мөгаллимнәре Марат хәзрәт Гыйльмановны, Рөстәм хәзрәт Нургалиевны, Рамил хәзрәт Гыйззәтуллинны бүләкләде.

Юбилей чарасында Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Россиядәге илчесе Маадад Хареб Мегейр Җәбер Әл-Хәйилиның, ТР Фәннәр академиясе, Россиянең башка төбәк мөфтиятләре һәм вузлары вәкилләре дә котлаулар белән чыгыш ясады.

# «Ни хәлең бар, хәзрәт?»

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте вәкилләре, казыйлар, мәдрәсә җитәкчеләре, яшь имамнар һәм журналистлар авыл имамнарын борчыган мәсьәләләргә багышланган түгәрәк өстәлгә җыелды.

Очрашуның сәбәбе дөрестән дә бик җитди булды. Милләтебезнең иманын, йөз аклыгын саклаучы мәчетләр бүгенге көндә имамнар җитмәүдән тилмерә. Сүз, билгеле, авыл мәчетләре турында бара. Аларга бүгенге көндә бик күп һәм мөһим вазифалар йөкләнгән: вәгазь тыңлау урыны булып кына калмыйча, алар гыйлем учаклары, тәрбия үзәкләре дә булып тора. Мәктәп укучыларының ялларын оештыру, ифтарлар, очрашулар, яшьләр өчен бәхәс клублары, имамнар җыелышлары, мәҗлесләр, тәрбияви чаралар дисеңме – болар барысы да мәчетләрдә уздырыла. Хәтта татар телен өйрәтү дә мәчетләргә кайтарылып калды! – дип билгеләде түгәрәк өстәлдә катнашучылар. Ә имамнар җитми…

Иң беренче сүзне Республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев алды. Җәлил хәзрәт сүзләренчә, авыл җирлекләренә имамнар җитмәүне, мәдрәсә бетергән шәкертләрнең туган җирләренә кайтмауларының сәбәпләре күбесенчә матди мәсьәләләргә кайтып кала: хезмәт хакы, социаль пакет булмау, мәчетләрне тәэмин итү өчен финанс чаралары җитмәү… Авылда гомер буе имам булып эшләгән кешегә киләчәктә лаеклы рәвештә пенсиягә чыгу мәсьәләсе дә килеп баса, дип ассызыклады баш казый.

– Бүгенге көндә республикабызда 1511 мәчет теркәлгән, – дип дәвам итте Мансур хәзрәт Җәләлетдин. – Әмма шуның алтмышы бикле тора, имамы юк. Имамнарның уртача яше 65 яшьтә һәм 700 мулланың дини белеме юк, әмма читтән торып белем алалар. Яшьләр мәдрәсәне бетергәч авылга атлыгып тормауларының сәбәпләрен аңлыйбыз. Шуңа да яшьләр өчен авыл җирлекләрендә төрле чаралар уздырырга дигән караштa торабыз. Соңгы егерме елда авылларда мәчетләрне эшмәкәрләр төзеде, ләкин хәзер мәчет төзү проекты белән килүчеләргә имам йорты булдыру мәсьәләсен дә күз алдында тотабыз». Мансур хәзрәт сүзләренчә, республикада яңа мәчетләр ачылып тора, өлкәннәргә алмаш кирәк – имамнарга ихтыяҗ һәрвакыт булачак. Ул шулай ук дин белгечләрен вакыф системасының Россия законнары кысаларында тулы көчкә эшләгәндә матди ярдәм итеп булыр иде, дигән фикерен әйтте.

Кадрлар белән эш беренче чиратта мөселман мәгариф системасы белән бәйле. Мөфтинең мәгариф буенча урынбасары Рәфыйкъ хәзрәт Мөхәммәтшин Татарстан мәдрәсәләре тарафыннан дини кадрларны җитәрлек күләмдә әзерләнүе турында сөйләп узды. «Бездә мәдрәсәләр күп – Идел буе федераль округында беренче урында торабыз. Россиянең иң зур югары уку йортлары бездә урнашкан. Татарстан ислам уку йортларында өч меңнән артык шәкерт укый. Ачылган көннәреннән саный башласаң, һәрбер мәчеткә 5-6 имам әзерләп биргәннәрдер инде. Бездә мәдрәсә тәмамлаучыларның үз белгечлеге белән эшләүләре якынча 60 процент тирәсе. Әмма имамнарның унбиш процентының яше сиксәннән узган, ә алтмыш процентының дини белеме юк. Шуңа да муллаларга югары белем бирүгә зур басым ясыйбыз. Иң читене һәм иң авыры – мәдрәсә бетерүчеләрне авыл мәчетенә китерү. Шуңа да мең биш йөздән артык мәчетнең картасы булырга тиеш дип саныйбыз: анда мәктәп, балалар бакчасы, медпункт, авыл хуҗалыгы үсешенең торышы һәм кадрлар резервы әзерләнү-әзерләнмәүнең торышы күрсәтелергә тиеш». Рәфыйкъ хәзрәт сүзләренчә, авыл җирлеге өчен имамнар әзерләнү төбәк мәхәллә җитәкчелеге һәм мөхтәсибәтләр белән бергә алып барыла торган эш.

Татарстандагы иң зур һәм иң борынгы мәдрәсәләрнең берсе – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең проректоры Зөлфәт хәзрәт Габдуллин мәдрәсә турында Россиянең төрле төбәкләрен колачлавын әйтте. «Безнең мәдрәсәне бетерүче белгечләрне дини оешмалар гына түгел, дәүләт учреждениеләре дә биш куллап көтәләр. Мәсәлән, дәүләт архивына иске имляны белгән, метрика кенәгәләрен укып бирүче белгечләр кирәк. Балалар бакчаларына тәрбиячеләр җитми. Моннан тыш, авылда имамнар җитешми. Әмма барлык җирлекләр дә югары квалификацияле имамны каршы алырга әзерме соң: яшь белгечне тәэмин итәсе бар», – дип уртаклашты ул.

Тагын бер мәдрәсә җитәкчесе, «Ак мәчет» мөдире Рөстәм хәзрәт Шәйхевәлиев: «Халык фикереннән чыгып караганда, бер кешене генә белемле итеп бөтен проблема хәл ителми әле. Безгә дәүләт күләмендә карашны, мөнәсәбәтне үзгәртергә кирәк». Аның сүзләренчә, имам авылны оештырып, мәхәлләне туплап торырга тиеш. Эшне күрә белеп, бәяләнерлек уңай үрнәкләр күбрәк булсын иде.

Очрашуда имам эше күп яклап каралды. Мәчетнең төзеклеген кайгыртып, төрле хуҗалык мәшәкатьләре белән чабып, аларның дин эшчәнлегенә вакыт калмаулары турында да сүз кузгалды. Беренчедән, гап-гади генә газ хезмәте күп яктан кесәгә суга, икенчедән, күп документлар таләп ителә. Моннан тыш, башка инстанцияләргә тапшырыла торган документлар бихисап.

Шулай булуга карамастан, авыл җирлегендә имамлык хезмәтенә керешеп китүдән курыкмаучылар да юк түгел. Кукмара районы имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев – дүрт балалы 30 яшьлек имам. Ул Россия ислам институтын бетергәч тәвәккәлләп кечкенә авылда эшләргә тотынган. Шуның өстенә Кукмара – түгәрәк өстәлдә күтәрелгән мәсьәләләрне уңай чишеп барган районнарның берсе. Анда халык үз белдеге белән, үзаңлавы белән мәчетләр дә сала, имамын да сайлый, аңа ярдәм итеп тә тора. Кукмара районында берничә авылда хәмер сатылмавында да мөхтәсибәт, дин әһелләренең өлеше зур: Уразай, Аш-Буҗи, Туембаш авылында аракы юк икән! «Җирлек башлыклары белән дә очрашулар һәрдаим үткәрелә, уртага салып сөйләшүләр җомгадан соң хәл ителә», – дип сөйләде Рәдиф хәзрәт. Аның кордашы, Кукмараның Пычак авылы егете Илнур хәзрәт Кашапов та үзенең дин юлында күрсәткән эшләрен бәян кылды. Ул 42 хуҗалыклы авылда имам булып торуына карамастан, бернигә зарланмыйча, бар эшен җиренә җиткереп алып бара: фермерлык хуҗалыгын да тота, районда үрнәк имам да. Җомгаларга аның вәгазьләрен тыңларга кеп-кечкенә авылдан егермеләп кеше җыела. Илнур хәзрәт, зарланудан бигрәк, әүвәл тырышлык күрсәтү, халык белән бергә булуның әһәмиятле булуын әйтте. Эштә, төрле чараларда актив катнашу сорала. Гаилә, нәсел-нәсәбең дә бар халык алдында: кыек гамәлләр тиз күренә. Халык абруен казану өчен бар эшне җиренә җиткереп эшләү, күркәм әхлаклы булу кирәк, – дип билгеләде ул.

■ dumrt.ru





# Нәрсә ул әманәт?



Гарәп телендә әманәт сүзе намуслык, тугрылык, ышанычлылык дигәнне аңлата һәм хыянәт сүзенең антонимы булып тора. Ә хыянәт сүзе монафикълык, ялганлау дигәнне аңлата.

Әманәт – вакытлыча нәрсәне дә булса саклап тору. Әгәр дустың сиңа берәр нәрсәне: «Бу әйберне шул көнгә кадәр генә үзеңдә тот әле», – дип бирсә, син аңа үз әйбереңә караган кебек карарга, вакыты җиткәч, аны кайтарып бирергә тиеш. Диндә дә әманәтне шул яктан карап була һәм анда ул күп төрле була ала.

## Иң зур әманәт

Иң бөек әманәт ул – Ислам дине. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

**«Без әманәт итеп күкләргә, җиргә вә тауларга Ислам шәригатен тәкъдим иттек, ләкин алар кабул итмәделәр, әгәр үти алмасак, газап ирешер, дип курыктылар, бу әманәтне кеше көчсез булган хәлдә өстенә йөкләде».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:72

Пәйгамбәрләр үзләренә иңгән вәхиләрнең сакчылары булып торалар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мин монда (Аллаһының) вәкиле булып торам, сез дә миңа ышаныгыз. Миңа күкләрдән иртән вә кичен вәхи иңеп тора», – дип әйткән. Пәйгамбәрләрдән соң килгән галимнәр өчен дә динне тарату әманәт санала.

## Аллаһы Тәгалә биргән барлык нигъмәтләр – әманәт

Бу нигъмәтләргә дөнья байлыклары да, кешенең тән әгъзалары да, күрү, ишетү, тоемлау сәләтләре дә керә. Шуңа күрә бу әманәтләрне Аллаһы риза булан эшләрдә генә кулланырга кирәк. Шулай ук аларны куллануда соңга калмаска яхшырак. Аллаһ илчесе галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Сиңа 5 төрле нәрсә килгәнче икенче бишнең кадерен бел: үлемең килгәнче исән булуыңның, авыру килгәнче сәламәтлегеңнең, берәр эш белән мәшгуль булганчы буш вакытыңның, картлыгың килгәнче яшь чагыңның, фәкыйрьлек килгәнче байлыгыңның». Саналып киткән 5 әйбер дә әмантә керә. Алар белән дөрес файдалана белергә кирәк. Әгәр кеше үзенең көч-куәтен һәм буш вакытын ярамаган эшкә юнәлтсә, сәламәт булганда изге гамәлләр кылмыйча йөрсә, картайганчы, яшь булганда гыйлем алмаса – болар барысы да әманәткә хыянәт итү булып санала.

Шәригатьнең 5 максаты турында ишеткәненгез бардыр. Моның турында вәгазьләр дә күп булды, китапларда да күп язылды. Шулай да кыскача гына аларны искә төшереп китәсем килә. Беренчедән, шәригать динне саклый, икенчедән кешенең гомерен, җанын, өченчедән, кешенең акылын, дүртенчедән кешенең малын саклый. Һәм бишенче әйбер итеп кешенең дәрәҗәсен саклый. Ягъни дин шуларны сакларга юнәлтелгән, шуңа да бу әйберләрне саклау – һәр кешенең мөһим бер эше, чөнки болар барысы да безгә әманәт.

Чыннан да, кешенең гомере аңа әманәт итеп бирелгән, шуңа күрә ул аны да юкка сарыф итәргә тиеш түгел. «Әле мин яшь» дигән ялгыш фикерләр белән яшәргә ярамый. Кеше берәр әманәт тапшырса, аның вакытын да билгели. Гомер дә билгеле бер вакытка гына бирелә. Кешенең намусы, дәрәҗәсе, акылы – әманәт. Шуңа да хәмер эчеп, акылны капларга, бозык гамәлләр кылып, намусны җуярга һич ярамый.

## Гыйлем алу, аны тарату – әманәт

Кыямәт көнендә гомере, малы, гыйлеме, тәне турында соралмыйча бер генә кеше дә аягын да атлый алмас. Моның турында пәйгамбәребез хәдисләре хәбәр итә. Моннан чыгып, гыйлемне алу, аны тарату, аның буенча гамәл кылу – болар барысы да әманәт.

Әйе, кешенең тәне – әманәт. Аллаһы Тәгалә безгә аны да кулланып торырга гына бирде. Вакыты беткәч, аны да кабергә урнаштырабыз. Үз тәнеңә игътибар итмәү – әманәткә каршы бару дигән сүз. Авырса, дәваларга, аңа рәсемнәр ясамаска, мәсәлән, татуировка, вакытында ашарга, организмга зыян килә торган итеп күп ашмаска, вакытында йокларга кирәк. Бу очракта гына ошбу әманәт әйбәт саклана дип әйтеп була.

## Кешеләргә йөкләнелгән эш, хезмәт – әманәт

Эш кушканда, ул эшне башкарып чыга алырлык кешеләргә генә кушу кирәк. Кешегә авыр эш, яки нинди дә булса бер эштә белме булмаган кешегә йөкләргә ярамый. Ягъни берәр вазифаны шул вазифага лаек булган кешегә генә тапшырырга ярый. Эш йөкләнелгән кеше дә бу эшне җиренә җиткереп башкарырга тиеш. Кешеләрнең үзләренә йөкләнелгән әманәтләрне башкармау – Кыямәт көненең кече билгеләреннән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әманәт (саклау) югалса, Сәгатьне көтегез», – дип әйткән. Сәхабәләр: «Ул ничек итеп югала?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез: «Эшләр лаексыз кешеләргә тапшырыла башлагач, Сәгатьне көтегез», – дип җавап кайтарган.

## Сакларга биреп торган әйбер – әманәт

Әгәр дә берәр кеше үз әйберсен икенче бер кешегә сакларга, дип биреп торса, аны саклау һәм беренчел халәтендә кайтарып бирү – әманәт.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дип әйтә: «Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Бервакыт бер кеше үзенә җир сатып ала һәм анда бер ваза алтын таба. Ул бу алтынны кире хуҗасына кайтарырга тели һәм: «Мин сездән җирне генә сатып алдым», – дип әйтә. Җир хуҗасы исә: «Мин сиңа җирне анда булган бар әйбере белән бергә саттым», – дип әйтә. Шуннан соң алар казый янына баралар. Казый аларның балалары турында сорый. Берсенең улы, икенчесенең кызы барлыгы ачыклана. Казый аларга: «Аларга никах укыгыз һәм акчаны аларга тотыгыз. Шулай ук бу акчадан сәдакалар да бирегез»,– дип җавап кайтара.

Әманәт гаилә тормышында да зур урын биләп тора. Ир-атка аның хатыны, хатын-кызга аның ире әманәт. Ата-ана өчен балалары шулай ук амәнәт. Өйдәге серләр, мал, җенси мөнәсәбәт мәсьәләсе – болар да әманәт.

Хакимгә ул идарә иткән ил әманәт. Директорга – аның кул астында эшләгән хезмәткәрләр. Гаилә хуҗасына – аның гаилә згъзалары. Васыять үтәү – шулай ук әманәт. Кемгәдер сәлам ирештерергә кушсалар, шул сәламне ирештерү – әманәт.

## Әманәтләрне кайтарып бирү тиешле

Әманәт – саклар өчен билгеле бер вакытка биреп торган әйбер дидек. Шәригать бирелгән әманәтне сакларга һәм аны тиешле рәвештә кире кайтарып бирергә боера: **«Дөреслектә, Аллаһы сезгә әманәтләрен әһелләренә тапшырырга әмер итәдер».**

«Нисә / Хатыннар», 4:58

Бу аятьне тәфсир кылып, Ибне Кәсир болай дип әйтә: «Бу барлык әманәтләргә дә кагыла. Алар ике категориягә бүленә: Аллаһы каршында булган әманәтләр – намаз, ураза һ.б. Һәм Аллаһының колларының әманәтләре, мәсәлән, кемнеңдер сакларга биреп торган әйберләре.

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә: **«Ий мөэминнәр! Аллаһыга вә Расүлгә хыянәт итмәгез һәм үзара әманәтләрегезгә дә хыянәт итмәгез, вәхәлән ки, аның хыянәт икәнен үзегез беләсез»,** – дип әйтә.

«Әнфәл / Табыш», 8:27

Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам монафикъ кешеләрне тасфирлап, болай дип әйтә: «Монафикъның билгесе өчтер: әгәр сөйләсә, алдалый; килешү төзесә, вәгъдәсендә тормый; әгәр әманәткә берәр нәрсә бирсәләр, әманәтенә хыянәт итә». Гомумән алганда, әманәткә беркайчан да хыянәт итәргә ярамый. Ул куелган вакыт эчендә кире кайтарылырга, ике якның да хакларына зыян салмаска тиеш. Сатып алабызмы, сатабызмы; арендага алганда һәм биргәндә, залог калдырганда, аны саклап торганда да хаклар кайтарылырга тиеш.

Әманәткә хыянәт итү – зур гөнаһлар рәтенә керә. Имам Әз-Зәһәби: «Хыянәт – нинди генә эштә булуына карамастан, бик пычрак гамәлдер», – дип әйтә. Әманәтләрне барыбызга да намус белән үтәргә насыйп булсын. Әмин!

**■ Сәхифәне Габделхәким Фәсхиев әзерләде**

# Дүртенче тугры хәлифә – Гали радыяллаһу ганһе



## Ислам динен кабул итүе

Гали радыяллаһу ганһе беренчеләрдән булып Ислам динен кабул итә. Әбү Талибның картаюы сәбәпле көче, игътибарлыгы җитми башлагач, Галине Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тәрбиягә ала.

Бер көне Гали радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез галәйһиссәлам белән Хәдичә радыяллаһу ганһәнең намаз укыганнарын күрә дә: «Әй, Мөхәммәд, бу нинди дин?» – дип сорый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Бу Аллаһының дине. Ул бу динне сайлады һәм аны кешеләргә ирештерер өчен илчеләр җибәрде. Мин сине Аллаһыга гыйбадәт кылырга, Лат белән Гуззәне калдырырга чакырам», – дип әйткән. Гали радыяллаһу ганһе аңа: «Минем бу хакта бер дә ишеткәнем юк, әтиемнән сорарга кирәк», – дип җавап кайтара. Аллаһының Илчесе үзенең сере таралуын теләми, шуның өчен дә ул Галигә: «Әй, Гали, әгәр Исламны кабул итмәсәң, моның турында беркемгә дә әйтмә», – дип үтенә. Гали ул төнне ислам дине хакында уйланып чыга, бу серне саклый. Аллаһы Тәгалә аның күңелендә Ислам диненә мәхәббәт уята. Шулай итеп, Гали радыяллаһу ганһе 10 яшендә Ислам динен кабул итә.

## Гали радыяллаһу ганһенең һиҗрәте

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе дә һиҗрәт кылырга теләгәч, иптәш итеп Әбү Бәкер радыяллаһу ганһене сайлый. Гали радыяллаһу ганһене исә әманәтләрен тапшырырга, йомышларын үтәргә вәкил итеп калдыра. Корәешлеләр Мөхәммәд галәйһиссәламне үтерергә дип өен чолгап алуларына карамастан, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән сөекле Расүлебез йортыннан гына түгел, ә Мәккәдән дә имин рәвештә чыгып китә. Гали радыяллаһу ганһе исә Расүлуллаһның киемнәрен ябынып, гомерен дә корбан итәргә разый булып, аның урынында ятып йоклый. Аңа да мөшрикләр тарафыннан бернинди дә зыян ирешми. Расүлуллаһның әманәтләрен үтәгәч, ул үзе дә Мәдинәгә җәяүләп һиҗрәт кыла. Күп йөрүдән аяклары ярылып, канап бетә. Мөхәммәд галәйһиссәлам аны күреп, бик кызгана һәм аның өчен дога кыла.

## Гали радыяллаһу ганһенең тыйнаклыгы

Гали радыяллаһу ганһе сәхабәләр арасында иң тыйнакларыннан санала. Ул беркайчан да тамагы туйганчы ашамый. Ашаган ризыгы да бик гади була. Моның турында аннан сорагач, ул: «Бу саранлык сәбәпле түгел, бәлки мин үземә җиткәнен генә һәм шөбһәсез ризыкны ашарга тырышам», – дип җавап кайтара торган булган.

Кием-салымына килгәндә, гадәттә ул эченә таш бәйләп йөргән. Шул таш киеменә ышкылып, киемен ерткан очраклар да булган. Шул вакытларда ул үзенең мәшһүр кылычын биреп, кием алган. Соңыннан, акчасы булгач, кылычын яңадан сатып алган.

Ул кыска һәм ямаулы киемнәр кигән. Кайбер мөселманнарга ул: «Мин моны мөселманнар миңа иярсеннәр өчен һәм калеб хошугълы булсын өчен киям», – дип әйткән. Кышын исә җылы кием таба алмыйча туңып йөргән.

## Гали радыяллаһу ганһенең Аллаһы юлында сугышуы һәм батырлыгы

Гали радыяллаһу ганһе тарихта Гали батыр исеме астында мәгълүм. Ул Тәбук сугышыннан кала Пәйгамбәребез галәйһиссәлам булган барлык сугышларда да катнаша. Тәбук сугышында Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны Мәдинә әмире итеп калдыра.

Бәдер сугышында Гали радыяллаһу ганһе гаскәр алдына чыгып сугыша һәм үзенең дошманын иң беренчеләрдән булып җиңә.

Өхед сугышында ул Мөхәммәд галәйһиссәламне якларга дип иң беренчеләрдән булып килеп җитә.

Бәни Курайза сугышында Гали радыяллаһу ганһе байрак йөртүче була.

Хайбар сугышында да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа байракны тоттырып: «Бу байракны Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесе яраткан кешегә бирәм», – дип әйтә.

## Гали радыяллаһу ганһенең хәлифәлеге

Гали радыяллаһу ганһе 656 елда (һиҗри белән 35 нче елда) хәлифәлеккә килә. Ул хәлифәлек эшен үзенә кадәр булган Гомәр һәм Госман радыяллаһу ганһүмнәр заманындагы тәртип буенча дәвам иттерергә тели, ләкин Госман радыяллаһу ганһене үтергәннән соң килеп чыккан мәшәкать аңа тыныч кына идарә итәргә бирми. Шам әмире Могавия Галигә буйсынудан баш тарта. Ул Гали радыяллаһу ганһегә: «Иң элек Госманны үтерүчеләрне җәзага тартырга кирәк. Әгәр шулай итсәң, мин сиңа бәйгать бирермен», – дип әйтә.

Гали радыяллаһу ганһе белән Могавия арасында килеп чыккан низаг көннән-көн үсә. Бу каршылыкларга түзә алмыйча Гайшә радыяллаһу ганһә Мәдинәдән чыгып китә. Могавия дә гаскәр белән чыга. Шул рәвешле, ике гаскәр бер-берсе белән очрашкач, арада булган фетнәчеләр яшерен рәвештә уклар җибәрәләр һәм ике гаскәр арасында сугыш чыга. Тарихта бу сугыш «Дөя сугышы» исеме астында мәгълүм.

Озакламый Могавия белән Гали арасында тагын бер бәрелеш була. Ул «Саффәйни сугышы» буларак мәгълүм. Бу ике сугышта 700 сәхабә шәһит китә һәм аларның күбесе Коръән-хафизлар була. Әлеге хәлләрдән соң Гали радыяллаһу ганһе Могавия белән килешүгә бара һәм Госманны үтерүчеләрне җәзага тарта. Тарихта алар хариҗиләр исеме астында мәгълүм. Гали радыяллаһу ганһе аларны җәзага тартса да, Могавия барыбер аңа буйсынмый. Хариҗиләр исә үз чиратында Галине үтерергә ант итәләр.

## Гали радыяллаһу ганһенең шәһит булып китүе

Гали радыяллаһу ганһе үзенең шәһит булып китәчәген белә, чөнки Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Син иң явыз кешеләр кулыннан китәчәксең», – дип әйткән була.

Хариҗиләрдән булган Габдрахман бине Мүлҗим аны үтерер өчен үзенең өлкәсендә булган иң оста үтерүчене таба. Ләкин ул кеше бу эшкә алынырга теләми. Габдрахман аңа: «Әгәр син Галине үтерсәң, сиңа җәннәт кенә була. Ул безнең абыйларыбызны, туганнарыбызны үтерде», – дигәч кенә ул ризалаша.

Гали радыяллаһу ганһе 63 яшендә шәһит булып китә һәм соңгы сүзләре Коръәннең түбәндәге аятьләре була:

**«Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер».**

«Зүлзилә / Җир Селкенмәк», 99:7-8

# Ашар алдыннан «Бисмилләһ» әйтүнең фазыйләте



«Бисмилләһ» – мөселман кешесе бик еш кабатлый торган иң мөһим догадыр, мөгаен. Шул дога белән ул барлык эшләрен Раббысының ихтыярына тапшыра, тәвәккәл кыла. «Бисмилләһ» әйтеп без йортыбызның ишекләрен ачып керәбез, шул ук сүзне ашар алдыннан кабатлыйбыз, гомумән, нинди генә эшкә тотынсак та, иң элек «Бисмилләһ»тән башлыйбыз. Гадәттәгечә, гап-гади ризык ашар алдыннан да иң әүвәл «Бисмилләһ» әйтергә кирәк, чөнки Аллаһының исемен искә алу ашый торган ризыгыбызга бәрәкәт иңдерә. Ләкин ашар алдыннан «Бисмилләһ» әйтүнең башка өстенлекләре дә бар, шул исәптән:

1. Мөселман кешесе шул рәвешле Пәйгамбәребез галәйһисәламнең сөннәтен үтәгән була.

Хәдистә: «Бисмилләһ әйт һәм уң кулың белән аша», – дип әйтелә.

2. Аллаһыны зикер итә.

Имам Тирмизи җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Ашый башлаганчы сезнең һәркайсыгыз: «Бисмилләһ», – дип Аллаһының исемен искә алсын. Әгәр ул Аллаһы Тәгаләнең исемен искә алырга оныт-са: «Бисмилләһи фи әүвәлиһи вә әхыйриһи (Әүвәлдә һәм ахырда Аллаһы исеме белән!)» – дисен».

3. Шайтаннан саклый.

«Әгәр кеше өенә кергәндә һәм ашаганда Аллаһы Тәгаләне зикер итсә (ягъни, «Бисмилләһ» дип әйтсә), Шайтан үзенең иярченнәренә: «Сезгә монда торырга урын да, ашарга ризык та юк!» – дип әйтер. Әгәр ул кеше өенә кергәндә Аллаһы Тәгаләне зикер итмичә керсә, шайтан үзенең иярченнәренә: «Сез сыеныр урын таптыгыз!» – дип әйтер. Әгәр ул ашаганда да Аллаһы Тәгаләне зикер итмәсә, Шайтан үзенең иярчен-нәренә: «Сез торырга урын да, ашарга ризык та таптыгыз!» – дип әйтер.

«Бисмилләһ» кәлимәсенең Шайтаннан саклавы хакында бик күп хәдисләрдә әйтелә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам янында ашап утырган бер кеше ризыгы бер кабарлык кына калганчы Аллаһының исемен искә алмый. Соңгы кисәкне авызына якын китергәч, ул: «Бисмилләһи фи әүвәлиһи вә әхыйриһи», – дип әйтә. Шуннан соң Аллаһының илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм көлеп җибәрә һәм: «Шайтан әлегә кадәр аның белән бергә ашады, ләкин ул Аллаһының исемен искә алгач, Шайтан бөтен ашаган ризыгын кире косып чыгарды», – дип әйтә.

Хөзәйфә мондый хәдис риваять итә: «Аллаһының илчесе белән бергә ашарга туры килгәндә, ул ашый башламыйча торып, безнең беребез дә ризыкка үрелми иде. Көннәрдән бер көнне шулай ашарга утыргач, безнең янга бер кыз килә. Ул, аны кемдер ашыктырган кебек, шунда ук ризыкка үрелеп кулын суза, ләкин Расүлуллаһ аны туктата. Соңрак безнең янга бер бәдәви килә һәм ул да ашыга-ашыга ризыкка кул суза. Пәйгамбәребез аны да кулыннан тотып өлгерә һәм: «Дөреслектә, Аллаһы исеме искә алынмаган ризыкны Шайтан үзенә хәләл саный. Бу ризыктан авыз итәр өчен ул шушы кызны, соңыннан әлеге бәдәвине монда китерә. Ләкин мин аларны кулларыннан тотып өлгердем. Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, мин әлеге ике кешенең кулын тоткан вакытта, чынлыкта мин шайтанның кулыннан тоттым», – дип әйтә. Шушы сүзләрдән соң Расүлуллаһ «Бисмилләһ» кәлимәсен әйтә һәм ашый башлый».

# Балаларда ничек Исламга мәхәббәт тәрбияләргә?

Балалар тәрбияләү – ул Аллаһы Тәгалә каршында бик зур җаваплылык. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Янә белегез, малларыгыз вә балаларыгыз фетнәдер, әмма Аллаһы юлында булганнарга Аллаһы хозурында олуг нигъмәтләр бар, малларыгызны вә көчләрегезне Аллаһы юлына тотыгыз!»**

«Әнфәл / Табыш», 8:28

Балаларда Аллаһы Тәгаләгә, Аның диненә карата ничек мәхәббәт тәрбияли алабыз соң?

Әйдәгез, бергәләп уйлап карыйк: әгәр сез үзегез намаз укымасагыз, баланы өйрәтә аласызмы? Пәйгамбәребез галәйһиссәлам турында үзегез бернәрсә дә белмичә, аның турында балагызга нәрсәләр сөйләрсез?

Моннан аңлашылганча, сез үзегез белгән очракта гына баланы кызыксындыра һәм Аллаһы Тәгаләгә, Аның диненә карата мәхәббәт уята аласыз. Бала сезгә карап өйрәнә һәм сездән үрнәк алачак.

Ничек кенә булмасын, бала һәрвакытта да үзен тиешенчә тотмас, канәгатьсезлек тә күрсәтер. Бу очракта Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисен искә төшерик.

Берәү Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килеп: «Миңа киңәш-нәсыйхәт бир әле», – дип сораган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аңа: «Ачуланма!» – дип җавап биргән. Әлеге кеше соравын берничә мәртәбә кабатласа да, Аллаһының Илчесеннән шундый ук җавап алган.

Әлбәттә, иң камил тәрбияче – сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм. Без, үз чиратыбызда, аннан үрнәк алабыз.

Бер гыйбрәтле вакыйганы карап үтик.

Мәккәне яулаганнан соң күп кенә корәешлеләр Ислам динен курку сәбәпле генә кабул итәләр. Алар арасында 16 яшьлек Саләмә бине Мөәммим атлы егет тә була. Бу егет бик күркәм тавышлы булган. Билал (беренче мөәзин) азан әйтергә дип Кәгъбәгә күтәрелгән. Корәешлеләр төркеме җыйнау-лашып утырганнар, алар арасында теге егет тә булган.

Билал азан әйтә башлагач, әлеге егет үз тавышының матурлыгын күрсәтергә теләп, үчекләргә тотынган. Кычкырып көлгән, башкаларны да көлдергән, хәтта көлгән тавышлары Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә дә ишетелгән.

Әгәр сезнең балагыз мәчеттә мөәзинне шулай үчекләсә, сез нишләр идегез? Барыннан да элек, аны кешеләр алдында бу гамәле өчен әрләгән булыр идегез.

Мөхәммәд галәйһиссәлам егетнең кылган гамәле турында ишетеп: «Аны минем яныма китерегез», – дип әйткән. Егет куркып калган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам янына килгәч, Аллаһының Илчесе аңа: «Синең матур тавышың турында миңа хәбәр ирешде. Телисеңме, мин сине азан әйтергә өйрәтәм?» – дип әйткән.

Егет ризалашкан һәм Аллаһының Илчесе барлык кеше алдында аңа азан өйрәткән. Егет бик куанган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә моңа бик шатланган.

Соңрак бу егет үзе сөйләгән: «Аллаһы белән ант итәм, мин азан әйтергә өйрәнгәч, «Бу Аллаһының Илчесе!» – дип әйттем». Пәйгамбәр галәйһиссәлам егеттән: «Мәккә халкы өчен мөәзин буласың киләме?» – дип сораган. Егет: «Әйе», – дип җавап кайтарган. Шуннан соң Аллаһының Илчесе: «Син – Мәккәнең мөәзине!» – дип әйткән.

Бу егет әлеге вакыйганы Пәйгамбәребез галәйһиссәлам вафатыннан соң сөйләгән: «Мин әлегә көнгә кадәр Мәккә мөәзине. Әгәр Пәйгамбәр ул чагында минем белән шулай эшләмәсә, мин динсез булып үләр идем», – дип әйткән.

Нәкъ менә шундый хикмәтле ысуллар белән Пәйгамбәребез галәйһиссәлам балаларда Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның диненә карата мәхәббәт уята алган. Без дә аңардан үрнәк алсак иде.

***Лилия Хәләфетдинова***

Элек-электән шәрык медицинасы табиблары җан белән тән бергә бәйләнгән дип әйтеп килгәннәр, ягъни тән авырулары безнең эчке халәтебезнең нинди булуыннан тора. Моның чыннан да шулаймы икәнен белер өчен, без «Бәби клуб» балалар үзәге җитәкчесе Алсу Камалова белән әңгәмә корырга булдык.



# ЭМОЦИЯ ҺӘМ АВЫРУ

**– Әссәләмү галәйкүм, Алсу. Сез үзегезнең үзәктә турыдан-туры ата-аналар белән дә эшлисез. Аларга бала тәрбияләү буенча киңәшләрегезне бирәсез. Менә бу буыннар элемтәсе, тәрбияләгән вакытта барлыкка килгән эмоциональ элемтә сәламәтлеккә ничек тә булса тәэсир ясый аламы?**

– Вәгаләйкүмуссәлам. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләне барлык эшләребездә дә беренче урынга куйсак, калганнары да үз урынында булачаклар. Без моның турында бик күп очракларда онытып җибәрәбез, ахры. Авыруларга килгәндә, алар – тормышыбызда ниндидер дөрес булмаган гамәл кылганыбызны исебезгә төшерә торган әйбер дисәк тә була. Аллаһы Тәгалә безгә шул рәвешле торышыбызны күрсәтә, чөнки һәрбер авыру – ул бер сынау, ул – чистарыну, моның турында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә әйтеп уза. Шулай итеп, авыру – без сакларга тиеш булган, безнең өчен мөһим булган әйберләрне үзенә күрә бер искә төшерү. Икенче төрле әйткәндә, монда кеше белән трансформация башлана, әмма бу әйберләрне бик тирән итеп аңлатасым килми. Әмма, әйе, эмоциональ элемтә ул бар; ул турыдан-туры тәэсир итә торган элемтә. Һәм әгәр дә без (ата-аналар) моны алдан ук дөрес итеп күрергә өйрәнсәк, вакытында шөкер итә белсәк, авыруларны вакытында дәваларга тотынсак, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, без туарга мөмкин булган бик күп проблемалардан котыла алыр идек.

**– Балаларның сәламәтлеге нәрсәдән башлана соң?**

– Балалар турында сүз чыкканда, шуны әйтәсем килә: без кайчандыр барыбыз да бала булган кеше, аларның сәламәтлеге гаиләдәге мохиттән башлана. Әни кешегә – әни ролендә, әтигә – әти, әби-бабайга – әби-бабай ролендә булырга кирәк. Гаиләдәге рольләр алышынмаска тиеш. Әмма кайчакларда әти кеше үз роленнән чыгып, укытучы, критик ролен ала. Әни кеше әти ролен алып, гаиләдән читләшә башлый. Әти кешене өйрәтергә, гаиләне тәэмин итәргә тырышып, гаиләдән еракламаша. Һәм шушы вакытта Аллаһы Тәгалә төрле сигналлар аша безгә бу проблеманы күрсәтә. Бала – ата-ана мөнәсәбәтендәге бер фильтр булып тора. Һәм инде урта яшьтәге балалар белән вакытында сөйләшеп, (кече яшьтәге балалар белән бүтән төрле эш итәргә кирәк) аны борчыган мәсьәләләр турыда фикер алышсаң, бик күп авырулардан котылып була. Минем үземнең балаларыма да берсенә 6, икенчесенә 9 яшь. Без һәрвакытта аларны борчыган мәсьәләләр турында алар белән сөйләшеп торырга тырышабыз. Һәм гаиләдәге ниндидер бер проблеманы булдырмый калу, яки булганын үстерми калу – күп кенә авыруларга барлыкка килмәскә ярдәм итә. Без, әлхәмдүлилләһ, авырмыйбыз да диярлек. Бу – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, әлбәттә.

**– Авыруны алдан ничек кисәтеп була соң?**

– Нинди генә авыру булмасын, ул үз-үзең белән ихлас булудан яки булмаудан башлана. Күп очракта без күңелебездә булган әйберләрне күрсәтмичә яшәргә тырышабыз. Булган хисләребезне эчкә йотып, картинаны матур итеп ясарга тырышабыз. Мәсәлән, хатын-кыз үзенең иренә булган ачуын күрсәтмәскә мөмкин, киресенчә, елмаеп, булмаган хисләрне бар дип, матур итеп аралашырга тырыша. Шулай итеп начар хисләрне эчендә саклый. Һәм дөрес аңлагыз, мин аларга кычкырышырга, талашырга, эчтә булганны акырып тышка чыгарырга кушмыйм. Юк, бу очракта гади сөйләшү кирәк. Сөйләшеп, аңлашып алу кирәк. Менә бу сөйләшү эчтәге начар хисләрнең авыруга әйләнмәвенә бер адым булачак. Тормышыбызда бик күп очракларда без бу приемнан баш тартабыз, әйбәтләп, чын күңелдән сөйләшә алмыйбыз.

Балалар белән дә шулай ук. Без алар белән дә шулай ук ихлас рәвештә төрле сөйләшүләр алып барырга тиешбез. Аларга: «Сиңа балалар бакчасында нәрсә ошамады? Сиңа мәктәптә бүген нәрсә ошамады?» – ише сораулар бирергә була. Бик еш без үзебезнең балаларыбызны ишетмибез дә. Бала кайтып: «Минем балалар бакчасына барасым килми», – дип әйтә ала. Без аны болай гына барасы килмидер дип уйлап, аның сүзләренә игътибар да итмибез. Без аның ни өчен барасы килмәгәнлеген белергә дә тырышмыйбыз. Без, киресенчә, балабызны балалар бакчасына барырга кирәклеген, яки мәктәпкә йөрергә кирәклеген аңлата башлыйбыз. Аны мәҗбүри итеп куябыз. Әмма шушы гамәлебез белән без баланы авыруга таба бер адым ясатабыз. Авыру – организмда булган бер төрле көчсезлекнең, көчсез органның нәтиҗәсе генә. Әлбәттә, һәр кешенең организмы төрле була, кеше үзе дә төрле була. Бу дөньяны күзләре белән күргән кешеләр бар. Бу дөньяны колаклары белән күргән кешеләр бар. Бу дөньяны борыннары белән дә күргән кешеләр бар. Без бит һәрберебез дә төрле-төрле. Кемдер өчен көчсез булган орган – күз. Кемдер өчен – борын. Әлбәттә, моның турында психологиядә аерым бер бүлек бар, моңа да тирән итеп керәсем килми. Әмма кай җирдә юкарак, ул җир беренче булып тишеләчәк бит. Шуңа да, әгәр без бу өлкәне бер өйрәнеп алсак, Пәйгамбәребезнең бу мәсьәләгә карата булган сөннәтен өйрәнсәк, бу безгә авыруларны җиңәргә бик зур ярдәм булыр иде.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренең тормышына күз салыйк. Әгәр дә алар арасында берәр төрле низаг килеп чыкса, алар моның нәтиҗәсен Кыямәт көненә калдырмаганнар. Алар бер-берсенә барып, сәбәпнең нидә булганын, ни аркасында араларында бәхәс купканын аңларга тырышканнар.

Бүгенге көндә исә, кешеләрдә хисләрне эчкә бикләп кую процессы бара. Әмма кеше эчендә булган ачу белән ни эшләргә белми әле. Ул аны эчендә саклый, әмма юкка чыгару процессы белән ул таныш түгел. Кешеләр эчендә булган хисләрне тыныч кына, ихлас һәм дөрес итеп аңлатып бирә белмиләр. Шул ук ир белән хатын мөнәсәбәтен алсак, без бер-беребезгә дә бөтен дөреслекне сөйләп бирә алмыйбыз. Безгә, мәсәлән: «Әйе шул, мин бераз гына көнләшеп алдым», – дип әйтү дә зур кыенлык тудыра. Әмма күптән түгел генә бер хәдис укыдым. Анда Пәйгамбәребез: «Үз хатынын көнләмәгән кеше бездән түгел», – дип әйткән. Чыннан да, бу гади әйбер. Кем үзенең хатынын көнләми ди инде? Әмма без аны кайчакта әйтми калабыз, кыенсынабыз. Ирләребезнең кайберләре: «Әйе, менә мин сине бераз көнләп алдым әле», – дип ихластан әйтә дә алмыйлар. Әгәр ир-атка берәр нәрсә ошамый башласа, ул, гадәттә, аны сүз белән әйтми. Ул өйнең җыештырмаганлыгына, ризыкның тоссыз булуына бәйләнә башлый. Ә чишмәнең башы дип әйтик, ягъни иренең үзен шулай тоту сәбәбе – хатын-кызның бүтән бер гамәлендә була ала. Хатыны ире көткәндә елмаймаса да, ир кешедә менә шушындый реакция була ала. Үзеңне шул рәвешле ябып тоту, ул юрган белән ябынган кук. Без, чыннан да, үзебезнең үпкәләребез, курыккан әйберләребез, авыруларыбыз турында сөйләргә бик теләмибез, чөнки без, кеше моны белгәч, аны безгә каршы кулланыр дип куркабыз. Кеше безнең турында күбрәк белгән саен, үзеңне зәгыйфрәк тоя башлыйбыз. Һәм кеше үзеннән-үзе үзен көчле итеп күрсәтә башлый. Әмма без бер әйберне онытып җибәрәбез: безнең көчсезлегебездә дә көч бар. Әгәр дә үзебезнең көчсезлекне ихлас рәвештә күрсәтә белсәк, янәшәбездә яшәүче кеше дә безгә карата саклык белән караячак. Аның мөгамәләсе дә йомшак булачак. Шуңа бөтен әйберне алдан сөйләшергә тырышырга кирәк. Әни булсын, әти булсын, нинди генә якын кеше булмасын – алар барысын да аңлыйлар.

**– Әңгәмәгез өчен зур рәхмәт.**

– Үзегезгә рәхмәт, сау булыгыз.

***дәвамы бар***

■ **Хузур ТВ**

# Дөньядагы иң үзенчәлекле мәчетләр

Бүгенге көндә җир йөзендә нинди генә мәчетләр юк. Кайберләре бик борынгы булулары, башкалары салынган урыннары яки материалы белән үзенчәлекле булып торса, аерым мәчетләрнең төзелү тарихлары да бик гаҗәеп. Әлбәттә, аларның барысын да тасвирлап бетерү мөмкин түгел, без кайбер үзенчәлекле мәчеткә тукталып китәрбез.


## Балчыктан ясалган җәмигъ мәчет



Африкада урнашкан Мали дәүләтенең борынгы Җәннә шәһәрендә балчыктан дөньядагы иң зур бина төзелгән. Бу бина – мәчет һәм 1988 елда ул ЮНЕСКО бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән.

Җәннә шәһәрендә беренче мәчет 1200–1330 еллар аралыгында салына, дигән фикер бар. Ә әлеге балчык мәчет 1909 елда төзелеп бетә. Гыйбадәтханәнең размерлары – 75х75 м, ә манарасының биеклеге – 16 метр тирәсе. Мәчет каршында мәдрәсә дә эшләп килә. Бүгенге көндә бу бина туристларны да бик кызыксындыра, әмма дәүләттә кабул ителгән кагыйдәләр буенча, мәчетләргә фәкать мөселманнар гына керә ала.

## Җир астында урнашкан мәчетләр



Дөньяда җир астында урнашкан мәчетләр аз түгел. Шундыйларның берсе Казахстанның көнбатышында, Мәңгистау җирлегендә урнашкан Бекет-ата мәчете.

Бекет-Ата исемле әүлия 1750 елда туа, Хивада гыйлем ала, дини гыйлемнәр белән беррәттән, ул физика, математика, астрономияне дә яхшы белгән, дип сөйлиләр. Барлыгы ул дүрт мәчет төзи. Шуларның берсе Огланды ызанындагы кыяда уеп ясалган һәм җир астына төшеп китә. Бекет-Атаның мөридләре күп булган. Бүгенге көндә дә бу шәхесне зур ихтирам белән искә алалар, мәчетен һәм каберлеген зиярәт итәргә киләләр.

Җир астында урнашкан мәчетләр шулай ук Россиядә, Дагъстан территориясендә дә очрый.

Истанбулда бик борынгы «Җир асты җәмигы» бар. Ул Византия империясе чорыннан ук саклanып килә. Кайчандыр бу куышлык кирмәннең бер өлеше булып торган, шулай ук ул төрмә, сугыш кирәк-яраклары саклана торган урын, зират буларак кулланылган. Монда яу вакытында вафат булган сәхабәләрнең тәннәре табыла һәм булачак гыйбадәтханәдә каберстан (мавзолей) корыла. Ә XVIII гасыр уртасыннан ул мәчет буларак кулланыла башлый.

## Су астындагы гыйбадәтханә



Согуд Гарәбстанының Тәбука районында драйверлар диңгез төбендә «мәчет» булдыра. Бу гади генә корылма берничә пластик торбадан эшләнгән һәм «Тәүхид» исемен йөртә. Ничек кенә булмасын, драйверлар аны дөньядагы беренче су астындагы мәчет дип атый һәм хәтта анда намаз укыганнары да бар.

## Иң кечкенә мәчет



Дөньядагы иң кечкенә мәчетне ачыклау җиңел түгел. Мисал өчен, Африкада берничә кеше генә сыя торган корылмалар-мәчетләр турында мәгълүматлар бар. Ә татарстанлылар өчен дөньядагы иң кечкенә мәчет Яр Чаллы шәһәрендә урнашкан. Гыйбадәтханә Явыз Иван Казанны алганда вафат булган мөселманнар истәлегенә һәйкәл буларак Бөек Ватан сугышы ветераны Мисбах Гыймалетдинов тарафыннан 2002 елда салдырылган. Мәчет Казанның Кол Шәриф мәчетенә охшатып төзелгән, аның дүрт манарасы бар. Намаз залы нибары 10 квадрат метр булган гыйбадәтханәдә берьюлы 5–6 кеше генә намаз укый ала.

## «Бәллүр» мәчет

Ә менә Малайзиянең Каула-Теренггану шәһәрендә төзелгән мәчеткә 1500 дән артык кеше сыя. Дөньяда ул «бәллүр» яки «көзгеле» мәчет буларак билгеле һәм Ислам архитектурасының үзенчәлекле бер үрнәге булып тора. Гыйбадәтханә рәсми рәвештә 2008 елда ачыла. Әлеге бина тышкы яктан махсус көзгесыман пыяла белән капланган, шуңа күрә кояшлы көннәрдә ул балкып тора, ә тәннәрен махсус яктырткычлар нисбәтенә төрле төсләр белән яна. Көзгеләр аша мәчеткә җитәрлек яктылык керә, шулай ук, көзге кояш нурларын чагылдырганга күрә, бина эчендә эссе булмый, уңайлы температура саклана.

## «Sanki Yedim» мәчете




Бу мәчет Истанбул шәһәрендә урнашкан. Әлбәттә, Төркия борынгы һәм зур мәчетләргә бик бай, ә әлеге мәчет алар янында бик кечкенә күренергә мөмкин. Әмма бу гыйбадәтханә төзелү тарихы белән үзенчәлекле: аны Хәйреддин Хаҗи әфәнде сала. Бу кеше, базарга килеп, үзенә яшелчә, ит, татлы ризыклар алырга теләгәен саен, алардан баш тартып, акчасын «Sanki yedim» («Әйтерсең лә ашадым») сүзләре белән (яки шул сүзләр ясалган махсус тартмага) җыеп куя торган була. Еллар дәвамында шул рәвешле ул мәчет салдырырга акча җыеп бара. Үзенең кечкенә кибете урынында ул мәчет төзи, бу йорт әлегәчә «Әйтерсең лә ашадым» исемен йөртә.

***

Шул рәвешле, без кайбер үзенчәлекле гыйбадәтханәләргә күзәтү ясадык. Хәдис шәрифтә: «Дөньяда мәчет төзегән кешегә Аллаһы Тәгалә җәннәттә йорт төзер», – диелә. Без дә, башкалардан гына көтеп утырмыйча, үзебезнең мәчетләребезне чиста-пакь тотсак, яңа Аллаh ыйортлары салынуына сәбәпләр кылсак иде.

■ **Сәхифәне Рәмзилә Шафикова әзерләде**

# Һава, җил, су...

Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясын яраткач, безне ялгыз итеп калдырмады. Барлыкка китергәннән алып, бүгенге көнгә хәтле барлык кирәк-ярак белән тәэмин итеп, кешелекне тәрбияләп тора. Аллаһы Тәгалә кешегә яшәр өчен кирәк булган нигъмәтләрне бик күп күләмдә һәм «бушка» бирә. Буш сүзе бу очракта бераз сәер яңгыраса да, бу – шулай. Кешегә йөрер өчен аяк бирелгән, әмма ул үзенә бу эшне җиңеләйтер өчен машина, самолет, көймә сатып алырга мөмкин. Кеше янындагы кешесе белән күзгә-күз карап сөйләшә ала, ә ерактагы кеше белән элемтәгә чыгарга бүгенге көндә телефоннар, компьютерлар ярдәмгә килә. Әмма һәрнәрсәнең бәясе бар. Машиналарның да ничәдер йөз меңнән башлап, миллионнар белән тәмамланганнары бар һ. б.

Бүгенге мәкаләбездә без алдарак әйтеп киткән, кайбер «бушка» килгән әйберләр турында сөйләшербез. Беренчесе – һава. Һава – безнең тормышыбыз өчен су кебек бик кирәкле, бик кыймммәтле элементларның берсе. Җир шарында яшәүчеләрнең, яши торганнарның бик күпләренә, ә бәлки барысына да яшәр өчен һава кирәк. Күзгә күренми торган булса да, физика галимнәре элек-электән бу элемент белән кызыксынып килделәр. Мәктәп елларын исегезгә төшерегез. Анда физика укытучылары һаваның массасын үлчәп күрсәтәләр. Беренче тапкыр моны күргәч: «Һаваның массасы була ала микән? Ник соң без аны тоймыйбыз?» – дигән сораулар белән үз-үзеңне тирән фикергә чумдырасың. Чыннан да, кызыклы, күп кеше өчен өйрәнелмәгән дә, әмма шул ук вакытта, барлыгы турында онытып та көн саен сулаган һавабыз бик кирәкле һәм әһәмиятле.

# Һаваны тоеп буламы?

Әйе, була. Машинада барганда, күп кешенең тәрәзәдән кулын чыгарып, җил «тотып» барганы бардыр. Шул вакытта кулыбыз һава белән каршылыкка очрашып, без һаваны тоемлый башлыйбыз. Дөрестән дә, һаваны иң җиңел тоемлау ысулы – җил. Җил чыккач, агачлар хәрәкәткә килә, тузаннар күтәрелә. Һәм моның сәбәбе бик тиз һава агымы – җил. Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәримдә җил турында болай дип әйтә:

**«Дәхи, болытны китерә (болытны баета) торган җилне җибәрдек вә күктән яңгыр индереп, сезне суга тук иттек, боларны сез булдыручы вә саклаучы да түгелсез, фәкать Безнең рәхмәтебездәндер».**

«Хиҗер», 15:22

Аллаһы Тәгалә болытны баета торган, болытларны сулы итә торган җил җибәрдек, дип әйтә, ә ул болытлардан, үз чиратында, җиргә яңгыр явып, аннан кешеләр дә, җәнлекләр дә, үсемлекләр дә үзләренә ризык табалар. Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә җилнең күплек санын – җилләр дип куллана, чөнки тәфсир кылучылар әйтүенчә, бу бәрәкәт китерә торган, файдалы җил. Мондый җилләр исеп, шулай ук агачларны, үсемлекләрне дә серкәләндерәләр.

Гомәр Әл-Ләйс болай дип әйтә: «Аллаһы Тәгалә җир себерә торган җил җибәрә. Аннан соң Ул болытларны югары күтәрә торган җил җибәрә. Аннан соң Ул болытларны бер формага китерә торган җил җибәрә. Аннан соң шул болытларны баета торган, аннан үсемлекләрне, агачларны серкәләндерә торган болыт җибәрә», – дип әйткән.

Икенче бар аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Ул – Аллаһы, рәхмәте белән шатландырыр өчен, яңгырдан алда җил җибәрер. Ул җил яңгырлы авыр болытны алып килсә, ул болытны үлгән, үләнсез җир өстенә сөрербез, ул җиргә яңгырны яудырырбыз вә ул яңгыр белән төрле җимешләрне чыгарырбыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:57

Чыннан да халыкта «яңгыр җилләре исә» дигән гыйбарә бар. Үз бакчасы, кырлары булган кешеләргә ул бик сөенечле хәбәр булып тора. Җырларда җилләр сәлам тапшыручы ролләрен дә үтиләр. Бу очракта, җилләр – яңгыр килә дигән куанычлы хәбәр алып киләләр.

# Бу нигъмәтләрне Аллаһы Үзе саклый



«Хиҗер» сүрәсендәге аятьне дәвам итеп, Аллаһы Тәгалә суны саклаучысы да Без дип әйтте. Авыл җирлекләрендә яшәүчеләр чишмәнең кадерен бик яхшы беләләр. Кайчакларда чишмәләрне ясыйбыз дип, суны «качырган» очракларны да күргәнебез бар. Чишмә бераз аскарак китә һәм авыл эчә торган сусыз да кала ала. Шуңа күрә чишмәләрне чүпләрдән саклап, карап торырга кирәк. Элегрәк, өйләребездә кер юу машиналары барлыкка килгәнче, авыл халкы кер чайкарга дип, чишмәләргә йөри иде. Хәзер чишмә матурлык урыны булып кына кала бирә. Ә кайбер авылларда чишмәләр, гомумән, юк. Аларга кое казырга туры килсә дә, аның суы чишмәнеке кебек саф булмый. Ничек кенә булмасын, чишмәләр дә, кое да суны җир астыннан бирә. Аллаһы Тәгалә «Мүлек» сүрәсендә суның аска качуы турында кисәтеп, су кача калса, аны кире чыгаручысы бары тик Аллаһы Тәгалә Үзе икәнен әйтеп уза. Һәм Аллаһыга шөкер, Аллаһы Тәгалә безгә әле дә чишмәләрдән, коеларыбыздан суларны биреп тора. Ел әйләнәсендә кешеләр дә, хайваннар да, үсемлекләр дә шушы нигъмәтләрдән файдаланып, гомер итәләр. Һәм алда әйтеп үтелгәнчә, болар барысы да бушка бирелгән бик кадерле нигъмәтләр икәнен истән чыгармасак иде.

# Һава булмаса, җил булмас иде

Һава булмаса, җил булмас иде, шулай булгач, кешелек һаваны элек-электән сулар өчен генә түгел, ә тормышының төрле өлкәләрендә дә кулланган. Беренче корабларны исегезгә төшерегез, аларның парусларына җил кирәк булган. Тегермәннәр эшләсен өчен дә җил кулланганнар. Учак та һава булмаган җирдә яна алмый. Кошлар да һава ярып очалар, самолетлар да шул ук системага корылган. Шарлар күккә менә алсын өчен дә һава кирәк.

Бу процесслар барысы да безне әйләндереп алган атмосферада булганлыктан, аны саклау зарури булып тора. Ислам динендә бер кызыклы кагыйдә бар: «Мөһим булган әйберләрне саклар өчен кирәкле булган әйберләр, үзләре дә мөһим булалар». Кешелеккә яшәр өчен, гомерен саклап калыр өчен җир дә, һава да, су да кирәкле, ә, димәк, алар үзләре дә мөһим әйберләр. Безгә болар турында уйланып, Аллаһы Тәгаләнең нигъмәтләренә шөкер кылучылардан булырга кирәк.

Шуннан соң Аллаһы Тәгалә: **«... вә күктән яңгыр индереп, сезне суга тук иттек ...»** – дип дәвам итә. Ягъни кешеләргә эчәргә яраклы, төче су җибәрелү турында сүз бара. Шулай итеп икенче бер нигъмәт – су нигъмәте.

Моңа Аллаһы Тәгалә кешеләрнең игътибарны «Вакыйга» сүрәсендә юнәлтә: **«Әгәр белсәгез, эчә торган суларыгыздан хәбәр бирегез! Ул суны болыттан сез индердегезме, әллә ул суны индерүче Безме? Әгәр Без теләсәк, ул суны эчәргә яраксыз итеп ачы кылыр идек, сез ни өчен шөкер итмисез?»**

«Вакыйга / Хәл», 56:68-70

Дөрестән дә, Аллаһы Тәгаләгә диңгезләрдән пар белән бергә тозны да менә торган итеп кылу, берни тормый. Әмма ул эчәргә яраксыз булыр иде.

■ Сәхифәне Габделхәким Фәсхиев әзерләде

## «Хозур» нәшрият йорты китап сату нокталарын арттыра

Габдулла Тукай урамы буенча урнашкан 36 йортта «Хозур» нәшрият йортының тагын бер китаплар сату ноктасы ачылды. Бу кибеттә дә Ислам буенча бик күп традицион дини әдәбият тәкъдим ителә.

Бүгенге көндә «Хозур» нәшрият йорты китаплары халык арасында киң тарала, китапларның төрлелеге көннән-көн арта бара һәм аларның һәрберсе Татарстан Диния нәзарәтенең голәмәләр шурасы тарафыннан тикшерү уза.

Сатуда төрле дини сорауларга җавап бирерлек фәнни китаплар, гарәп теле өйрәнүчеләр өчен дәреслекләр, дини-фәлсәфи китаплар, татар дин әһелләренең хезмәтләре дә бар. Басмалар күбесенчә ике телдә – татар һәм рус телләрендә чыга. Төрле яшьтәге, төрле гыйлем дәрәҗәсендәге кешеләр дә бу кибеттә үзләренә кирәкле китапны табыр, дип ышанып калабыз.

**Габдулла Тукай, 36 нчы йорт буенча урнашкан «Хозур» нәшрият йорты кибете көн саен иртәнге 9 дан алып, кичке 6 га кадәр эшли.**

**Китаплартурындатулыракмәгълүматны huzurshop.ru сайтында табарга мөмкин.**



«Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2019 елның икенче яртысына язылу башланды

- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42

### КАЗАН ӨЧЕН ГЫЙНВАР АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз: Сәхәр тәмам | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01.01.2019 | 05:53 | 06:43 | 08:13 | 12:00 | 13:33 | 15:20 | 17:18 |
| 02.01.2019 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:34 | 15:22 | 17:19 |
| 03.01.2019 | 05:53 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:35 | 15:23 | 17:20 |
| 04.01.2019 | 05:52 | 06:42 | 08:12 | 12:00 | 13:37 | 15:24 | 17:21 |
| 05.01.2019 | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:38 | 15:26 | 17:22 |
| 06.01.2019 | 05:52 | 06:41 | 08:11 | 12:00 | 13:39 | 15:27 | 17:23 |
| 07.01.2019 | 05:52 | 06:40 | 08:10 | 12:00 | 13:41 | 15:28 | 17:25 |
| 08.01.2019 | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:42 | 15:30 | 17:26 |
| 09.01.2019 | 05:51 | 06:39 | 08:09 | 12:00 | 13:43 | 15:32 | 17:27 |
| 10.01.2019 | 05:51 | 06:38 | 08:08 | 12:00 | 13:45 | 15:33 | 17:28 |
| 11.01.2019 | 05:50 | 06:37 | 08:07 | 12:00 | 13:46 | 15:35 | 17:30 |
| 12.01.2019 | 05:50 | 06:36 | 08:06 | 12:00 | 13:48 | 15:36 | 17:31 |
| 13.01.2019 | 05:49 | 06:35 | 08:05 | 12:00 | 13:50 | 15:38 | 17:32 |
| 14.01.2019 | 05:48 | 06:34 | 08:04 | 12:00 | 13:51 | 15:40 | 17:34 |
| 15.01.2019 | 05:48 | 06:33 | 08:03 | 12:00 | 13:53 | 15:42 | 17:35 |
| 16.01.2019 | 05:47 | 06:32 | 08:02 | 12:00 | 13:55 | 15:44 | 17:37 |
| 17.01.2019 | 05:46 | 06:31 | 08:01 | 12:00 | 13:56 | 15:45 | 17:38 |
| 18.01.2019 | 05:45 | 06:30 | 08:00 | 12:00 | 13:58 | 15:47 | 17:40 |
| 19.01.2019 | 05:45 | 06:28 | 07:58 | 12:00 | 14:00 | 15:49 | 17:41 |
| 20.01.2019 | 05:44 | 06:27 | 07:57 | 12:00 | 14:02 | 15:51 | 17:43 |
| 21.01.2019 | 05:43 | 06:26 | 07:56 | 12:00 | 14:03 | 15:53 | 17:45 |
| 22.01.2019 | 05:42 | 06:24 | 07:54 | 12:00 | 14:05 | 15:55 | 17:46 |
| 23.01.2019 | 05:41 | 06:23 | 07:53 | 12:00 | 14:07 | 15:57 | 17:48 |
| 24.01.2019 | 05:39 | 06:21 | 07:51 | 12:00 | 14:09 | 15:59 | 17:50 |
| 25.01.2019 | 05:38 | 06:20 | 07:50 | 12:00 | 14:11 | 16:01 | 17:51 |
| 26.01.2019 | 05:37 | 06:18 | 07:48 | 12:00 | 14:13 | 16:03 | 17:53 |
| 27.01.2019 | 05:36 | 06:16 | 07:46 | 12:00 | 14:15 | 16:06 | 17:55 |
| 28.01.2019 | 05:35 | 06:15 | 07:45 | 12:00 | 14:17 | 16:08 | 17:56 |
| 29.01.2019 | 05:33 | 06:13 | 07:43 | 12:00 | 14:19 | 16:10 | 17:58 |
| 30.01.2019 | 05:32 | 06:11 | 07:41 | 12:00 | 14:21 | 16:12 | 18:00 |
| 31.01.2019 | 05:30 | 06:09 | 07:39 | 12:00 | 14:23 | 16:14 | 18:02 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Декабрь саны, №12 (281)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2756
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 26 нчы декабрьдә таратыла.
График буенча бу санга 25 нче декабрь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.